ТАТАРСТАН.

БЕЗ БЕРГӘ

МЫ ВМЕСТЕ

2022 ГОД КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ НАРОДОВ РОССИИ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА 170 ТӘН АРТЫК МИЛЛӘТ ВӘКИЛЕ ЯШИ

Татарлар
Руслар
Чувашлар
Удмуртлар
Мордвалар
Марилар
Украиннар
Башкортлар
Азәрбайҗаннар
Үзбәкләр
Әрмәннәр
Таҗиклар
Белоруслар
Еврейлар
Алманнар
Казахлар
Грузиннар
Кыргызлар
Молдаваннар
Төрекмәннәр
Кореялылар
Лезгиннар
Чегәннәр
Төрекләр
Греклар
Поляклар
Чеченнар
Осетиннар
Коми-пермяклар
Аварлар
Даргиннар
Вьетнамнар
Литвалылар
һәм башкалар

В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН ПРОЖИВАЮТ ЛЮДИ БОЛЕЕ 170 НАЦИОНАЛЬНОСТЕЙ

ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

Татары
Русские
Чуваши
Удмурты
Мордва
Марийцы
Украинцы
Башкиры
Азербайджанцы
Узбеки
Армяне
Таджики

Белорусы
Евреи
Немцы
Казахи
Грузины
Киргизы
Молдаване
Туркмены
Корейцы
Лезгины
Цыгане
Турки

Греки
Поляки
Чеченцы
Осетины
Коми-пермяки
Аварцы
Даргинцы
Вьетнамцы
Литовцы
и другие

УДК 39(470.41)
ББК 63.529(2Рос.Тат)
Т 23

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ

ISBN 978-5-6046009-4-8
© Татарское детское издательство, 2022

ТАТАРСТАН.

БЕЗ БЕРГӘ

2022 ГОД КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ НАРОДОВ РОССИИ

МЫ ВМЕСТЕ

КАЗАНЬ
2022

КАДЕРЛЕ ДУСТЫМ!

Татарстан халыкларының мәдәнияте – республикабызның олы байлыгы, чөнки ул 170 тән артык халыкның мәдәнияте.

Синең алдыңда уникаль китап. Бу Татарстанның иң күп санлы халыклары – руслар, татарлар, чувашлар, удмуртлар, мордва һәм мариларның күптөрле һәм гаҗәеп мәдәни дөньясына сәяхәт.

Син бу халыкларның тормышы һәм көнкүреше турында күп нәрсә белерсең, аларның мәдәни гореф-гадәтләре һәм традицияләре, теле, музыкасы, милли ризык һәм киемнәренең үзенчәлекләре никадәр кабатланмас һәм гүзәл икәнлеген күрерсең. Шул ук вакытта син барлык халыкларга хас уртаклыкның да булуын белерсең. Аларны тарих, кунакчыллык һәм өлкәннәрне ихтирам итүгә нигезләнгән уртак традицияләр һәм, әлбәттә инде, ата-бабалары яшәгән җир – аларның бөек Ватаны – Россия берләштерә.

Татарстан халыклары күп гасырлардан бирле бергә, бер-берсен хөрмәт итеп, килешеп, дус-тату яшиләр. Безнең көчебез һәм горурлыгыбыз шушы бердәмлектә.

ДОРОГОЙ ДРУГ!

Культура народов Татарстана – великое богатство нашей республики, ведь это культура более 170 народов.

Перед тобой уникальная книга. Это путешествие в удивительный и многообразный мир культуры самых многочисленных народов Татарстана: русских, татар, чувашей, удмуртов, мордвы и марийцев.

Ты узнаешь много интересного о жизни и быте этих народов, увидишь, как прекрасны и неповторимы их культурные обычаи и традиции, их язык, музыка, особенности национальной кухни и одежды. В то же время ты увидишь, что у всех народов есть много общего. Их объединяют история, единые традиции, главные из которых – гостеприимство и уважение к старшим, и конечно, любовь к земле, на которой жили их предки, к их великой родине – России.

Много веков живут народы Татарстана вместе в дружбе, согласии и уважении друг к другу. В этом единстве и есть наша сила и гордость!

Милли бизәкләр һәм орнаментлар

Бик борынгы заманнарда, әле язу булмаган вакытларда, кешеләр әйләнә-тирә предметларга, аерым мәгънә салып, гади бизәкләр һәм орнаментлар ясаган.

Гасырлар узу белән, бизәкләр күпкә катлаулырак һәм төрлерәк була барган. Нәкъ элеккечә, төрле символларга тылсым көче биреп, хәзер алар белән йортларны, көнкүреш әйберләрен, киемнәрне бизиләр.

Бизәк ул – сызык һәм фигуралардан торган сурәт. Бизәк рәсемен теләсә нинди тәртиптә урнаштырырга мөмкин.

Бизәкләрне кеше генә түгел, табигать тә барлыкка китерә ала. Мәсәлән, тәрәзәләрдә кышкы могҗизалы бизәкләрне синең бик күп тапкырлар күргәнең бардыр.

Орнамент төрле предметларны бизәү өчен хезмәт итә. Безгә латин теленнән кергән әлеге сүз үзе дә «бизәк» дигәнне аңлата.

Орнамент, как и узор, служит для украшения различных предметов. Да и само слово, пришедшее к нам из латинского языка, означает «украшение».

ORNAMENTUM (лат.)

Национальные узоры и орнаменты

Татар бизәге
Татарский узор



Орнамент – аерым детальләр чиратлаша һәм кабатлана торган бизәк ул.

Орнамент – это узор, в котором чередуются и повторяются отдельные детали.

В глубокой древности, когда письменности ещё не существовало, люди уже рисовали на окружающих предметах простые узоры и орнаменты, вкладывая в них особый смысл.

Спустя тысячелетия узоры стали более сложными и многоцветными. Теперь ими украшают дома, предметы быта, одежду, по-прежнему придавая разным символам магическую силу.

Узор – это изображение из линий и фигур. Рисунок узоров можно располагать в любом порядке.

Узоры могут создавать не только люди, но и природа. Например, причудливые морозные узоры, которые ты наверняка видел не раз зимой на окнах.

МИЛЛИ БИЗӘКЛӘР ҺӘМ ОРНАМЕНТЛАР



Мари орнаментында атлар сурәтләнеше

Изображение коней в марийском узоре

Чуваш орнаментында ат сурәтләнеше

Изображение коня в чувашском узоре

Халык орнаментлары традицион символлардан тора. Һәр халыкта ул аерым. Шуңа да карамастан, мәгънәсе белән төрле милләт кешеләренә якын һәм аңлаешлы булганнары да бар.

Кешеләр көндәлек тормышта үзләрен уратып алган әйберләрне – кояш, күк йөзе, чәчәк; ат, үрдәк, әтәч һ. б. йорт хайваннарын сурәтләгән. Халыкларның күп гасырлар дәвамында яхшы күршеләр булып яшәүләре дә мәдәни традицияләр алмашуга ярдәм иткән. Менә шуңа күрә Идел буе халыкларының орнаментлары үзгә булса да, охшашлыклар да бар.

Народные орнаменты состоят из традиционных символов. У каждого народа они свои. Но есть и такие, значение которых близко и понятно людям любой национальности.

Люди изображали то, что окружало их в повседневной жизни: солнце, небо, цветы, домашних животных (лошадей, уток, петухов и т. д.). Да и доброе соседство народов на протяжении многих столетий помогало обмену культурными традициями. Вот почему орнаменты многих народов Поволжья при всём своём отличии имеют и некоторое сходство.

Кояш символы.
Мордва бизәге

Символ солнца.
Мордовский узор

Кояш символы.
Рус бизәге

Символ солнца.
Русский узор

Кояш символы.
Чуваш бизәге

Символ солнца.
Чувашский узор

Кояш символы.
Мари бизәге

Символ солнца.
Марийский узор

МИЛЛИ БИЗӘКЛӘР
ҺӘМ ОРНАМЕНТЛАР

РУС ОРНАМЕНТЛАРЫ

Әгәр дә рус орнаментларына игътибар белән карасаң, аларда кызыл һәм ак төсләрнең еш кулланылуын күрергә мөмкин. Андый сайлау очраклы түгел.

Осталар бу төсләргә аерым бер мәгънә биргән.

Кызыл төс ул – яшәү, ут, кояш төсе. Кызыл төстәге орнаментлар изге саналган, аларда тылсымлы дәвалау көче бар дип уйлаганнар. Шуңа күрә андый орнаментлы әйберләрне талисман буларак кулланганнар.

Ак төс ул – чисталык һәм азатлык төсе. Ак төстәге символларны кара көчләрдән саклану чарасы буларак файдаланганнар.

Тормыш агачы
Древо жизни



Галәм символы
(Алатырь йолдызы)
Символ Вселенной
(звезда Алатырь)

Бәхет символы
Символ счастья

Рус орнаментлары
Русские орнаменты

РУССКИЕ ОРНАМЕНТЫ

Если внимательно посмотреть на русские орнаменты, то можно заметить, что чаще всего в них используются красный и белый цвета. Такой выбор не случаен.

Мастера придавали этим цветам особый тайный смысл.

Красный цвет – это цвет жизни, огня и солнца. Орнаменты красного цвета считались священными, им приписывали магическую целебную силу. Поэтому вещи с таким орнаментом использовали как оберег (талисман).

Белый цвет – это цвет чистоты и свободы. Символы белого цвета использовали как защиту от тёмных сил.

19 нчы гасырга кадәр, орнамент һәм бизәкләр җете төстә булсын өчен, табигый буяулар кулланганнар.

Для того чтобы орнаменты и узоры были яркими, до 19 века использовали природные красители.

ТАТАР ОРНАМЕНТЛАРЫ

Татар орнаментлары үзләренең төрлелеге һәм күп төстә булуы белән аерылып тора.

Борынгы заманнардан ук татар орнаментларында чәчәк һәм үлән мотивлары чагылыш тапкан. Еш кына осталар канәфер, кыңгырау, мәк, ромашка кебек чәчәкләрнең сурәтләрен кулланган.

Татар орнаментында канәфернең сурәтләнеше
Изображение гвоздики в татарском орнаменте

Татар орнаментында кыңгырауның сурәтләнеше
Изображение колокольчика в татарском орнаменте

Татар бизәкләрен башка халыкларның орнаментларыннан контурлары буенча җиңел аерып була.

Татарские узоры и орнаменты можно легко отличить от орнаментов других народов по их контурам.

Татар орнаменты
Татарский орнамент

ТАТАРСКИЕ ОРНАМЕНТЫ

Татарские орнаменты знамениты своим разнообразием и многоцветием.

С древних времён главными в татарских орнаментах были яркие цветочные и растительные мотивы. Чаще всего мастера использовали изображения таких цветов, как гвоздика, колокольчик, мак, ромашка.

Гөлчәчәк, лалә, кашкарый сурәтләренә аерым мәгънә бирелгән.

Особое значение придавалось изображениям розы, тюльпана и астры.

Гөлчәчәк – матурлык һәм мәхәббәт символы

Роза – символ красоты и любви

Лалә – яңарыш символы

Тюльпан – символ возрождения

Кашкарый – озак яшәү символы

Астра – символ долголетия

Күренекле галим, этнограф, тарихчы һәм археолог Карл Фукс: «Татар хатын-кызлары кул эшләренә бик оста: алар эшләгән эскәтер, яулык һәм сөлгеләр гаҗәеп матур», – дип билгеләп үткән.

Известный учёный, этнограф, историк и археолог Карл Фукс отмечал: «Татарки – большие рукодельницы: скатерти, платки и полотенца их работы очень красивы».



МИЛЛИ БИЗӘКЛӘР
ҺӘМ ОРНАМЕНТЛАР

ЧУВАШ ОРНАМЕНТЛАРЫ

Буяу һәм фигураларның чын матурлыгын сез чуваш халык бизәкләре һәм орнаментларында таба алырсыз. Юкка гына Чувашияне «йөз мең чигеш һәм йөз мең бизәк ягы» дип атамыйлар.





Сигезпочмаклы йолдыз – кояш символы
Восьмиконечная звезда – символ солнца

Чувашларның халык орнаментларында осталар төрле мәгънә белдерә торган квадрат, өчпочмак, зигзаг һәм башка геометрик фигураларны еш кулланалар.



Чуваш орнаменты
Чувашский орнамент

ЧУВАШСКИЕ ОРНАМЕНТЫ

Настоящее великолепие красок и фигур вы найдёте в чувашских народных узорах и орнаментах.

Недаром Чувашию называют «краем ста тысяч вышивок и ста тысяч узоров».

«Тормыш агачы» бизәге
Узоры «Древо жизни»

В народных орнаментах чувашей мастера часто используют квадрат, треугольник, зигзаг и другие геометрические фигуры, которые имели разные значения.



Чуваш бизәкләренең традицион төсләре
Традиционные цвета чувашских узоров

УДМУРТ ОРНАМЕНТЛАРЫ

Бизәк һәм символлар удмуртлар тормышында зур роль уйнаган. Алар аша кешеләр үзләренең дөньяны аңлауларын, табигать белән бәйләнешләрен, хыялларын белдергән, илаһи көчләргә мөрәҗәгать иткән.

Образларның байлыгы һәм төрлелеге бүген дә этнограф һәм археологларны гаҗәпләндерә. Удмурт бизәкләрендә хайван, кош, чәчәк, йолдыз, планета образларын күрергә була. Һәрбер символ үзенең эчке мәгънәсенә ия. Мәсәлән, теге яки бу нәселгә карау, сәламәтлек, уңыш, уңдырышлылык, яклау символлары.

Зигзаглы ромб – дуслык символы
Ромб с зигзагами – символ дружбы

Ат – хезмәт сөючәнлек символы
Лошадь – символ трудолюбия



Кояш – яшәү символы
Солнце – символ жизни



Удмурт бизәкләрендә төсләрнең традицион ярашуы
Традиционные сочетания цветов в удмуртских узорах



Удмурт орнаменты
Удмуртский орнамент

УДМУРТСКИЕ ОРНАМЕНТЫ

Узоры и символы играли большую роль в жизни удмуртов. Через них люди выражали своё понимание мира, связь с природой, свои мечты и послания высшим силам.

Богатство и разнообразие образов и сегодня удивляет учёных-этнографов и археологов. В удмуртских узорах можно увидеть образы животных, птиц, цветов, звёзд, планет. Каждый символ имеет свой тайный смысл. Например, символы принадлежности к тому или иному роду, символы здоровья, удачи, плодородия, защиты.

Үрдәк символы
Символ утки



Йолдыз символы
Символ звезды



Ай символы
Символ луны



«Атлар» символы
Символ «Кони»

«Тормыш агачы» символы
Символ «Древо жизни»



Аккош символы
Символ лебедя

МОРДВА ОРНАМЕНТЛАРЫ

Мордва халыкларының иҗаты табигать белән тыгыз бәйләнгән. Кояш, чәчәк, агач, елга, кош, хайван образлары халык бизәкләре һәм орнаментларында еш очрый.

Зигзаг – су символы

Зигзаг – символ воды

Квадрат һәм ромблар – муллык һәм уңдырышлылык символлары

Квадраты и ромбы – символы изобилия и плодородия

Ата-бабаларның белемнәре «шифрланган» символлар, сакланып, буыннан буынга күчә бара. Шул сәбәпле без бүген күп гасырлар элек яшәгән кешеләрнең ничек гомер иткәннәрен, нәрсә турында хыялланганнарын, аллалардан нәрсәләр сораганнарын белә алабыз.



Мордва орнаменты

Мордовский орнамент

МОРДОВСКИЕ ОРНАМЕНТЫ

Творчество народов мордвы тесно связано с природой. Солнце, цветы, деревья, река, птицы, животные – эти образы чаще всего встречаются в народных узорах и орнаментах.



Сигезпочмаклы йолдыз –
кояш символы
Восьмиконечная звезда –
символ солнца

Мөгез рәвешендәге бизәк –
үлән һәм агачлар символы
Узор в виде рогов –
символ травы и деревьев

Символы, в которых «зашифровали» свои знания предки, бережно сохраняются и передаются из поколения в поколение. Поэтому сегодня мы можем узнать, как жили, о чём мечтали и просили богов люди, жившие многие столетия назад.



Мордва бизәкләренең традицион төсләре
Традиционные цвета мордовских узоров

МАРИ ОРНАМЕНТЛАРЫ

Башка халыклардагы кебек үк, мари бизәкләрендә дә тирән мәгънә яшеренгән, аларның бер өлеше явыз көчләрдән яклау буларак хезмәт иткән.

Яхшылык һәм уңдырышлылык символы, бөти

Знак добра и символ плодородия, оберег

«Өй каравылчысы» символы

Символ «Сторож дома»

Агач, яшәеш башлангычы символы

Символ дерева, начала жизни

Һәрбер сызык, һәрбер бөтеркә үз мәгънәсен белдерә һәм безгә бик күп кызыклы әйберләр турында «сөйли» ала, ә бергә кушылган символлардан торган бизәк тулы бер тарих яки әкиятне тапшырырга мөмкин.

Мари орнаменты

Марийский орнамент

МАРИЙСКИЕ ОРНАМЕНТЫ

Как и у других народов, символы в марийских узорах скрывают глубокий смысл, часть их служила оберегами от злых сил.

Каждая линия, каждый завиток имеет своё значение и может «рассказать» нам много интересного, а сложенные вместе в узор символы могут поведать целую историю или сказку.

Ат – хезмәт сөючәнлек һәм муллык символы

Лошадь – символ трудолюбия и достатка

Күбәләк – җиңеллек һәм нәфислек символы

Бабочка – символ лёгкости и нежности



Мари бизәкләренең традицион төсләре
Традиционные цвета марийских узоров

Милли киемнәр

Милли кием – халык мәдәниятенең мөһим өлеше. Элек кешенең ничек киенүенә карап, аның милләте, яше, шөгыле, баймы яки ярлымы икәнлеге турында белеп булган.

Бигрәк тә хатын-кызларның киеме җете төсләре белән аерылып торган. Һәрвакыт матур киенеп йөрсеннәр дип, кызларны бала чактан ук тегәргә һәм чигәргә өйрәткәннәр. Халык костюмнары милли чигешләр белән бизәлгән.

Ир-атлар костюмы хатын-кызларныкы кебек бизәкле булмаган. Гадәттә милли орнамент белән ир-атларның путалары гына бизәлгән.

Хәзерге вакытта көндәлек тормышта беркем дә милли киемнән йөрми. Аларны бары тик музейларда, халык җыр һәм бию ансамбльләре артистларында гына күрергә мөмкин. Әмма соңгы вакытта киемнәрдәге милли мотивлар модада. Хәзерге заман дизайнерлары киемнәрне милли стильдә тегә һәм аларны бизәү өчен еш кына халык бизәкләрен һәм орнаментларын куллана.

Национальный костюм

Национальный костюм – важная часть народной культуры. Раньше по тому, как был одет человек, можно было узнать о его национальности, возрасте, занятии, богат он или беден.

Особенно яркой была одежда женщин. Девочек с детства приучали вышивать и шить, чтобы они всегда были красиво одеты. Народные костюмы богато вышивались национальным орнаментом.

У мужчин костюм был не таким красочным, как у женщин. И национальным орнаментом обычно украшался только мужской пояс.

В наши дни уже никто не носит национальные костюмы в повседневной жизни. Их можно увидеть лишь в музеях или на артистах ансамблей народных танцев и музыки. Однако в последнее время стали модными народные мотивы в одежде. Современные дизайнеры шьют одежду в национальном стиле и часто используют народные узоры и орнаменты в качестве её украшения.

РУС МИЛЛИ КИЕМЕ

Ир-атлар күлмәгендә кыйгач яка һәм хатын-кызларда сарафан рус халык киеменең аерым бер үзенчәлеге булып тора.

Рус гүзәлләре йөзек һәм муенсалар тагарга яраткан, ә башларына кокошник кигән, асма бизәк – рясна таккан.



Билбау
Пояс



Тасма
Лента

Алъяпкыч
Передник

РУССКИЙ НАЦИОНАЛЬНЫЙ КОСТЮМ

Самой заметной и отличительной чертой русского народного костюма является косоворотка у мужчин и сарафан у женщин.

Русские красавицы любили украшать себя кольцами и ожерельями, а на голове красовались кокошник и рясна.

Кафтан
Кафтан

Сарафан
Сарафан

Күлмәк
Рубаха

ТАТАР МИЛЛИ КИЕМЕ

Татар костюмнары башка төрки халыклар костюмнарына охшаган. Төп кием ул – киң күлмәк һәм чалбар. Күлмәк өстеннән хатын-кызлар – камзул яки алъяпкыч, ә ирләр халат кигән.

Татар кызларын хәситә (төрле тәңкә, кыйммәтле ташлар, сәдәфләр белән бизәлгән тукыма бәйләвеч) бизәгән. Хәситәне кыз бала өчен аның туган көненнән җыя башлаганнар. Татар гүзәлләре чулпы (чәч толымына кушып үрелгән тәңкәләр) тагып йөргән.

Түбәтәй
Тюбетейка



Калфак
Калфак

Күлмәк
Рубаха

Ыштан
Штаны

ТАТАРСКИЙ НАЦИОНАЛЬНЫЙ КОСТЮМ

Татарский костюм очень похож на костюмы всех тюркских народов. Основа – это широкая рубаха и брюки. Сверху у женщин надевалась жилетка или фартук, у мужчин – халат.

Татарские девушки обязательно носили хаситэ – нагрудную перевязку из разных украшений. Хаситэ для девочки собирали с самого её рождения. Все девушки носили чулпы – подвески из монет, которые вплетались в косы.

Камзул
Камзол

Читек
Ичиги

Күлмәк
Платье

ЧУВАШ МИЛЛИ КИЕМЕ

Чуваш халык костюмының нигезе – ирләрдә кыска, хатын-кызларда озын күлмәк. Аның өстеннән алъяпкыч, кафтан яки халат кигәннәр. Бәйрәм киемнәрен мул итеп чигеш белән бизәгәннәр.

Чуваш хатын-кызларының башында һәрвакыт сәйләнһәм тәңкәләр белән бизәлгән конуссыман башлык – тухья балкыган. Традиция буенча, кияүгә чыкмаган кызлар очлы башлы тухья кигән, ә кияүдәге ханымнарның милли баш киеме очлы булмаган.

Тухья
Тухья

Күлмәк
Рубаха

Алъяпкыч
Передник



Билбау
Поясок

ЧУВАШСКИЙ НАЦИОНАЛЬНЫЙ КОСТЮМ

Основа чувашского народного костюма – белая рубаха, длинная у женщин и короткая у мужчин. Поверх надевали передник, кафтан или халат. Праздничную одежду богато украшали вышивкой.

У чувашских женщин на голове всегда красовалась тухья – национальный головной убор в виде конусообразной шапочки из бусин и монет. По традиции, незамужние девушки носили тухью с острым концом наверху, а девушкам, вышедшим замуж, предписывалось носить тухью с тупым концом.

Кафтан
Кафтан

Ыштан
Штаны

УДМУРТ МИЛЛИ КИЕМЕ

Удмурт милли киеме – чын сәнгать әсәре.

Удмуртлар озын күлмәк – дэрем кигән. Өске якка хатын-кызлар – алъяпкыч яки халат, ирләр кафтан кигән.

Удмурт чибәркәйләре тәреләр белән бизәлгән баудан муен бизәнгече – монисто таккан.

Күлмәк
Рубаха

Билбау
Пояс



Күкрәк бизәнү әйбере
Нагрудное украшение

УДМУРТСКИЙ НАЦИОНАЛЬНЫЙ КОСТЮМ

Удмуртский национальный костюм – настоящее произведение искусства.

Удмурты надевали длинную рубаху – дэрэм. Поверх женщины надевали передник или халат, мужчины – кафтан.

Удмуртские красавицы обязательно носили монисто – шейное украшение из шнура с крестами в виде ожерелья.



Айшон
Айшон

Сюлык
Сюлык

Оек
Чулки

Алъяпкыч
Передник

МОРДВА МИЛЛИ КИЕМЕ

Мордва халыкларында, кагыйдә буларак, милли кием чигеш һәм бизәнү әйберләренең күплеге аркасында бик авыр булган. Бу бигрәк тә хатын-кызга кагылган. Мондый киемне киеп йөрү үзе бер сәнгать саналган.

Мукшы һәм эрзяларның милли киемнәрендә аерымлыклар бар.

Мордва кызлары чигә бизәнгече – ак йоннан эшләнгән шарлар – сергтлар таккан. Кызларның шулай ук кабырчык, чигеш һәм төсле сәйләннәр белән бизәлгән итәк бәйләвече – пулокаркс та булган.

Күлмәк
Рубаха

Ыштан
Штаны

МОРДОВСКИЙ НАЦИОНАЛЬНЫЙ КОСТЮМ

У народов мордвы национальный костюм, как правило, довольно тяжёлый из-за большого количества вышивок и украшений. Особенно это касалось женщин. Носить его было своеобразным искусством.

В национальных костюмах мокши и эрзя были свои различия. Мордовских красавиц всегда отличали шарики у висков из белого пуха – сергт. Также девушки надевали пулокаркс – набедренную повязку, украшенную раковинами, вышивкой и цветным бисером.

Панго
Панго

Пулокаркс
(итәк бәйләвече)
Пулокаркс
(набедренник)



Билбау
Пояс

МАРИ МИЛЛИ КИЕМЕ

Мари милли киеменең төп детале булып, күлмәк һәм ыштан саналган. Ирләр күлмәге хатын-кызларныкына караганда кыскарак тегелгән, аның бизәлеше дә матуррак булган.

Күлмәк өстеннән мари хатын-кызлары алъяпкыч һәм кафтан кигән.

Мари хатын-кызларының милли киемен тәңкә, ялтыравык һәм сәйләннәр белән бизәлгән тукымадан ясалган күкрәкчә – яга бизәгән.



Шымакш
Шымакш



Теркупш
Теркупш

Билбау
Пояс

Марилар этник яктан берничә төркемгә – тау, болын, төньяк-көнбатыш һәм көнчыгыш мариларына бүленә.

Марийцы делятся на несколько этнических групп: горные марийцы, луговые, северо-западные и восточные.

МАРИЙСКИЙ НАЦИОНАЛЬНЫЙ КОСТЮМ

Основными деталями марийского народного костюма являются рубаха и штаны. У мужчин рубаха короче, чем у женщин, и расшита красочнее.

Поверх рубахи марийские женщины надевали передник и кафтан.

Национальный костюм марийских женщин украшал яга – нагрудник из ткани с нашитыми монетами, блёстками и бусинами.



Яулык
Платок

Күлмәк
Рубаха

Милли телләр һәм әдәбият

Милли тел – теләсә кайсы халыкның иң зур байлыгы. Анда милли мәдәният һәм милли характер чагылыш таба.

Татарстан Республикасында ике дәүләт теле бар – рус һәм татар телләре.

Тел – мәдәни мирасның бер өлеше, ул безгә ата-бабалардан калган.

Туган телеңне белү – үз илеңнең чын гражданины булу дигән сүз.

Һәр татарстанлының үз туган телен өйрәнү мөмкинлеге бар. Казандагы Халыклар Дуслыгы йортында Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе эшли. Анда төрле милләт кешеләре туган телләрен, үз халкының мәдәниятен, шулай ук башка халыкларның мәдәниятен өйрәнә.

Национальные языки и литература

Национальный язык – величайшее богатство любого народа. В нём отражаются национальная культура и национальный характер.

В Республике Татарстан два государственных языка – русский и татарский.

Язык – это часть культурного наследия народа, переданного нам предками.

Знать родной язык – значит быть настоящим гражданином своей страны.

Каждый татарстанец имеет возможность изучать родной язык. В Казани в Доме Дружбы народов есть Многонациональная воскресная школа, где люди разных национальностей изучают родные языки, культуру своего народа и языки, культуру других народов.

Халыклар Дуслыгы йортының якшәмбе мәктәбе бүлекләрендә түбәндәге телләр өйрәнелә:

азәрбайҗан	немец
ассирия	осетин
әрмән	поляк
башкорт	рус
грек	таҗик
грузин	татар
иврит	удмурт
мари	украин
мордва	чуваш

В отделениях воскресной школы Дома Дружбы народов изучают языки:

азербайджанский	немецкий
армянский	осетинский
ассирийский	польский
башкирский	русский
греческий	таджикский
грузинский	татарский
иврит	удмуртский
марийский	украинский
мордовский	чувашский

РУС ТЕЛЕ

Рус теле дөньяда иң күп таралган телләр исәбенә керә. Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан кебек илләрдә рус теле дәүләт телләренең берсе булып тора.

Рус теле ярты миллионнан артык сүз запасын туплаган иң аһәңле һәм бай телләрнең берсе санала.

РУССКИЙ ЯЗЫК

Русский язык относится к числу самых распространённых языков мира. В таких странах, как Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, русский язык является одним из государственных языков.

Русский язык считается одним из самых мелодичных и богатых языков, то есть обладающих большим запасом слов (более полумиллиона).

Бертуган Кирилл һәм Мефодий – славян мәгърифәтчеләре, рус теле һәм 100 дән артык телнең язуына нигез булган славян әлифбасы – кириллицаны төзүчеләр.

Братья Кирилл и Мефодий – славянские просветители и создатели славянской азбуки – кириллицы, на которой основана письменность более 100 языков, в том числе русского языка.

Александр Сергеевич Пушкин – күренекле рус шагыйрьләре һәм язучыларыннан берсе. Ул – хәзерге рус әдәби теленә нигез салучы. Аның әсәрләре дөньядагы күп телләргә тәрҗемә ителгән һәм дөнья әдәбияты классикасы санала.

Александр Сергеевич Пушкин – один из самых известных русских поэтов и писателей. Он стал основоположником современного русского литературного языка. Его произведения переведены на многие языки мира и являются классикой мировой литературы.

Халык сынамышлары, үткен язмалар, гаиләгә, дуслыкка мөнәсәбәт, кыюлык, кешелеклелек кебек сыйфатларга дан җырлау **халык мәкальләрендә** чагылыш таба. Шул сәбәпле Татарстанның төрле халыкларында мәкальләр бик охшаш.

Мәкальләрдә борынгы ата-бабаларыбызның табигатьне күзәтүләре, гасырлар дәвамында җыелып килгән хыял-өметләре көзгедәге кебек чагылыш таба.

Народные приметы, остроумные заметки, отношение к дружбе, семье, воспевание таких качеств, как смелость, доброта, – всё это нашло отражение в **народных пословицах**. Потому многие пословицы разных народов Татарстана очень похожи.

В пословицах, как в зеркале, отражаются наблюдения наших предков за природой, их мечты и надежды, которые складывались на протяжении многих веков.

РУС МӘКАЛЬЛӘРЕ

РУССКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Тырышкан табар,
ташка кадак кагар.
Без труда не вытащишь
и рыбку из пруда.

Эш беткәч, уйнарга ярый.
Сделал дело, гуляй смело.

Арбаны – кыштан,
чананы җәйдән әзерлиләр.
Готовь сани летом,
а телегу – зимой.

Йөз сум акчаң булганчы,
йөз дустың булсын.
Не имей сто рублей, а имей сто друзей.

МИЛЛИ ТЕЛЛӘР
һӘМ ӘДӘБИЯТ

ТАТАР ТЕЛЕ

Татар теле – Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең берсе. Татар теле Татарстанда иң киң таралган һәм сөйләшүчеләрнең саны буенча Россиядә икенче милли тел санала.

Татар теле төрки телләр төркеменең Идел буе-кыпчак төркемчәсенә карый.

ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

Татарский язык – один из государственных языков Республики Татарстан. Татарский язык является самым распространённым в Татарстане и вторым национальным языком в России по количеству говорящих на нём людей.

Татарский язык относится к поволжско-кыпчакской подгруппе тюркских языков.

Татар теленең хәзерге заман алфавиты кириллицага нигезләнгән, аңа өстәмә «Ә», «Җ», «ң», «Ө», «Ү» һәм «һ» хәрефләре кертелгән.

Современный алфавит татарского языка основан на кириллице, в которую добавлены дополнительные буквы: «Ә», «Җ», «ң», «Ө», «Ү» и «һ».

Изучай татарский вместе с героями мультфильма «Алты хәреф»!

Татар халкының яраткан шагыйре – **Габдулла Тукай.**

Татар әдәби теленә нигез салып, Тукай татар мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән. Татарстанда татар әдәбиятының күренекле классигын олылыйлар, 26 апрель – шагыйрьнең туган көнен республикабыз халкы Туган тел көне буларак билгеләп үтә.

Шагыйрь, беренчеләрдән булып, балалар өчен әдәби әсәрләр яза башлаган. Алар арасыннан иң атаклылары – «Шүрәле» һәм «Су анасы». Туган якка һәм туган телгә мәхәббәт белән сугарылган бу искиткеч әкиятләрне инде ничә буын белә һәм яратып укый.

Одним из самых известных и любимых народом татарских поэтов является **Габдулла Тукай**.

Тукай внёс огромный вклад в развитие татарской культуры, став основоположником литературного татарского языка. В Татарстане чтут великого классика татарской литературы, и день рождения поэта, 26 апреля, жители нашей республики отмечают как День родного языка.

Поэт одним из первых стал сочинять литературные произведения для детей. Наиболее известные из них – «Шурале» и «Су анасы». Вот уже несколько поколений знают и любят эти прекрасные сказки, наполненные любовью к родному краю и родному языку.

«Шүрәле» поэмасы геройлары

Герои поэмы «Шурале»

ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ

Кешегә чокыр казыма – үзең төшәрсең.

Не рой другому яму, сам упадёшь.

ТАТАРСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Ачның ачуы яман.

Страшен гнев голодного.

МИЛЛИ ТЕЛЛӘР
һӘМ ӘДӘБИЯТ

ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ

ТАТАРСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Киемеңә карап каршы алалар,
акылыңа карап озаталар.

По одёжке встречают,
по уму провожают.

Алма агачыннан ерак төшми.

Яблоко от яблони недалеко падает.

ЧУВАШ ТЕЛЕ

Чуваш теле – чувашларның милли теле. Чуваш алфавиты да, башка Идел буе халыкларының алфавитлары кебек үк, кириллицага нигезләнә. Анда үзенчәлекле «Ӑ», «Ӗ», «Ç», «Ӳ» хәрефләре бар.

ЧУВАШСКИЙ ЯЗЫК

Чувашский язык – национальный язык чувашей. Чувашский алфавит, так же как и алфавиты других народов Поволжья, основан на кириллице. В нём есть особые буквы: «Ӑ», «Ӗ», «Ç», «Ӳ».

Чуваш теле – болгар теле төркеменең бердәнбер тере теле.

Чувашский язык является единственным живым языком булгарской группы языков.

Иван Яковлевич Яковлев – хәзерге заман чуваш әлифбасын төзегән мәгърифәтче. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Иван Яковлевич үз халкына хезмәт иткән: балаларга чуваш телендә белем бирә торган халык мәктәпләре ачкан, чувашлар өчен чуваш һәм рус телләре дәреслекләре төзегән. Иван Яковлевның тырышлыгы нәтиҗәсендә чувашлар үз милли телләрендә китаплар чыгару мөмкинлегенә ия булган.

Иван Яковлевич Яковлев – чувашский просветитель и создатель современного чувашского алфавита. До конца жизни Иван Яковлевич служил своему народу: открывал народные школы с обучением детей на чувашском языке, составлял и выпускал учебники чувашского и русского языков для чувашей. Благодаря Ивану Яковлеву чуваши получили возможность печатания книг на национальном языке.

Борынгы заманнардан ук күп буыннар тарафыннан тупланган халык зирәклеге һәм тәҗрибәсе мәкаль һәм әйтемнәр аша тапшырылган.

С древних времен народная мудрость и опыт, накопленные поколениями, передавались через пословицы и поговорки.

ЧУВАШ МӘКАЛЬЛӘРЕ

ЧУВАШСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Дуслары булмаган кеше тамырсыз агач кебек.

Человек без друзей, что дерево без корней.

Кешеләрдән аз ал, күп бир.

Бери у людей мало, но давай много.

ЧУВАШ МӘКАЛЬЛӘРЕ

Яхшы дан байлыктан да кыйммәтрәк.

Добрая слава ценнее богатства.

ЧУВАШСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Ышанычлы дус бәяләп бетергесез.

Надёжный друг цены не имеет.

УДМУРТ ТЕЛЕ

Удмурт теле – удмуртларның милли теле. Удмурт теле, татар теле кебек үк, сүзләрдә басымның соңгы иҗеккә төшүе белән аерылып тора. Телдә рус һәм татар телләреннән кергән алынма сүзләр күп.

Удмурт алфавитында да үзенчәлекле хәрефләр бар: «Ӝ», «Ӟ», «Ӥ», «Ӧ», «Ӵ».

УДМУРТСКИЙ ЯЗЫК

Удмуртский язык – национальный язык удмуртов. Отличительной чертой удмуртского языка является ударение на последний слог слова, как и в татарском языке. В языке много русских и татарских слов.

В удмуртском алфавите также есть особые буквы: «Ӝ», «Ӟ», «Ӥ», «Ӧ», «Ӵ».

Кузебай Герд – удмурт әдәбияты классигы һәм удмурт балалар әдәбиятына нигез салучы, шагыйрь һәм язучы. Ул балалар өчен 80 шигырь һәм 50 дән артык хикәя язган. Кузебай Герд «Муш» («Бал корты») дип аталган беренче удмурт балалар журналы оештырган һәм аның мөхәррире булган.

Кузебай Герд – классик удмуртской литературы и основоположник удмуртской детской литературы. Поэт и писатель, он посвятил детям 80 стихотворений и свыше 50 рассказов. Кузебай Герд создал первый удмуртский детский журнал «Муш» («Пчела») и был его редактором.

Мәкаль кайчак халык турында хәтта иң зур күләмле әсәргә караганда да күбрәк сөйли.

Порой даже большое литературное произведение не расскажет о народе того, что можно узнать из его пословиц.

УДМУРТ МӘКАЛЬЛӘРЕ

УДМУРТСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Иң авыр эш – эшсезлек.

Самый тяжкий труд – безделье.

Сусыз мичкә дә кибә.

И бочка без воды рассыхается.

Кеше акылы белән озак яшәп булмый.

Чужим умом долго не проживёшь.

Халык эшли – син дә эшлә, халык бәйрәм итә – син дә бәйрәм ит.

Народ работает – и ты работай, народ гуляет – и ты гуляй.

МОРДВА ТЕЛЛӘРЕ

Мордва телләре – мукшы һәм эрзя халыклары телләре.

Ике телнең дә Урал телләре семьясының бер үк телләр төркеменә керүенә карамастан, аларда аерымлыклар шактый. Мәсәлән, исем һәм фигыльләр төрләнгәндә, бу телләрдә төрле кушымчалар ялгана. Шуңа күрә мукшы һәм эрзя һәрвакытта да бер-берсен аңлап бетермәскә мөмкин.

МОРДОВСКИЕ ЯЗЫКИ

Мордовские языки – это языки народов мокша (мокшанский) и эрзя (эрзянский).

Несмотря на то, что оба языка входят в одну языковую группу уральской языковой семьи, в них много различий. Например, в склонении существительных и спряжении глаголов в этих языках разные личные окончания. Поэтому мокша и эрзя не всегда могут понять друг друга.

Михаил Лукьянович Сайгин – мукшы халык язучысы, балалар китаплары һәм авылда яшәүчеләрнең тормышы турында танылган әсәрләр авторы. Аның китаплары рус, мари, чуваш, карел, удмурт һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән.

Михаил Лукьянович Сайгин – мокшанский народный писатель. Автор детских книг и известных произведений о жизни людей в обычном селе. Его книги переведены на русский, марийский, чувашский, карельский, удмуртский и другие языки.

Василий Кузьмич Радаев – эрзя халык шагыйре, прозаик, шул исемдәге мордва герое турындагы «Сияжар» халык эпосы авторы. Бу әсәргә материалны Василий Кузьмич бөтен гомере буена диярлек җыйган. Поэма мордва халыкларының хикәятләре нигезендә язылган.

Василий Кузьмич Радаев – эрзянский народный поэт, прозаик, создатель народного эпоса «Сияжар» о мордовском одноимённом герое. Материал для этого произведения Василий Кузьмич собирал почти всю свою жизнь. Поэма написана на основе сказаний мордовского народа.

Халык мәкальләре – һәр халык мәдәниятенең мөһим элементы. Алар буыннан буынга тапшырыла һәм кешелекле, дус, кыю, зирәк булырга өйрәтә.

Народные пословицы – важный элемент культуры любого народа. Они передаются из поколения в поколение и учат доброте, дружбе, храбрости и смекалке.

МОРДВА МӘКАЛЬЛӘРЕ

МОРДОВСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Ботаксыз – агач түгел,
баласыз – гаилә түгел.

Без веток – не дерево,
без детей – не семья.

Эш турында сөйләү җиңел,
эшләве авыр.

Легко о деле сказать,
да тяжело его сделать.

Туган якка юл да киң.

В родную сторону и дорога широка.

Ата-ана бәхете – бала бәхетендә.

Счастье родителей – в счастье детей.

МАРИ ТЕЛЕ

Мари теле элек чирмеш теле дип йөртелгән: мариларның элеккеге атамалары – чирмешләр.

Марилар берничә этник төркемгә бүленгәнлектән, аларның вәкилләренә төрле сөйләшләр хас: тау, төньяк-көнбатыш, көнчыгыш һәм болын мари телләре.

Төрле тел төркемчәләрендә булган марилар, әлифбалары туры килмәсә дә, бер-берсен яхшы аңлыйлар. Мәсәлән, болын мари телендә тау мари телендә булмаган «Ӈ» хәрефе бар. Аның каравы тау мари телендә башка телләрендә очрамый торган «Ӹ» хәрефе бар.

МАРИЙСКИЙ ЯЗЫК

Марийский язык раньше назывался черемисским: старое название марийцев – черемисы.

Поскольку марийцы делятся на несколько этнических подгрупп, их представители говорят на разных наречиях: горномарийском, северо-западном марийском, восточном марийском и луговом марийском.

Марийцы разных языковых подгрупп хорошо понимают друг друга, хотя их алфавиты и не совпадают. Например, в марийском луговом языке есть буква «Ӈ», которой нет в горно-марийском. Зато в алфавите горно-марийского языка есть буква «Ӹ», которая не встречается в других языках.

Ким Кириллович Васин – мари язучысы, педагог, әйдәп баручы әдәбият белгечләренең берсе, Мари Эл Республикасының халык язучысы. Рус язучыларының күп әсәрләрен мари теленә тәрҗемә иткән, энциклопедияләр төзүдә катнашкан.

Ким Кириллович Васин – марийский писатель, педагог, один из ведущих литературоведов, народный писатель Республики Марий Эл. Перевёл на марийский язык множество произведений русских писателей, участвовал в создании энциклопедий.

Халык мәкальләрендә күп буыннарның зирәклеге тупланган. Бер җөмләгә борынгы ата-бабаларыбыздан килгән тирән мәгънә сыйган.

В народных пословицах заключается мудрость многих поколений. В одной фразе умещается глубокий смысл, который дошёл до нас от наших предков.

МАРИ МӘКАЛЬЛӘРЕ

МАРИЙСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ

Аю үз өнендә көчле.

Медведь в своей берлоге силач.

Ялган сүз – өч көнгә,
дөрес сүз – гасырларга.

Ложное слово – на три дня,
правдивое слово – на века.

Өлкән кеше сүзе –
көмеш тәңкә.

Советы старшего –
серебряные монетки.

Атсыз хуҗалык
башсыз кеше кебек.

Хозяйство без лошади,
что человек без головы.

Күренекле шәхесләр

Һәр халыкта туган җирен, халкын үзенең хезмәте, таланты яки батырлыгы белән данлаган кешеләр бар.

Выдающиеся личности

У каждого народа есть люди, своим трудом, талантом или подвигом прославившие свой народ и землю, где они работали и творили.

Иван Иванович Шишкин – күренекле рус рәссамы. Алабугада туган. Иван Шишкин туган ягының әкияти матурлыгы сурәтләнгән пейзажлары белән дөньякүләм танылуга ирешкән. «Нарат урманында иртә», «Кораб урманы», «Арыш» һәм башка күп кенә картиналары Третьяков галереясында һәм Россиянең башка танылган музейларында саклана.

Иван Иванович Шишкин – выдающийся русский художник. Родился в Елабуге. Мировую известность Иван Шишкин получил благодаря пейзажам, в которых воспевал сказочную красоту родного края. Картины «Утро в сосновом лесу», «Корабельная роща», «Рожь» и многие другие хранятся в Третьяковской галерее и других знаменитых музеях России.



Шишкинның «Кораб урманы» картинасы. 1898 ел.
Картина Шишкина «Корабельная роща». 1898 г.

Шишкинның «Арыш» картинасы. 1878 ел.
Картина Шишкина «Рожь». 1878 г.

Фёдор Иванович Шаляпин – үзенең таланты белән дөнья опера сәнгатенә зур йогынты ясаган бөек рус опера җырчысы. Артистның таланты яшьли ачылган. Казан шәһәрендә ярлы гаиләдә туган Фёдор Шаляпин бала чактан татар моңнарын ишетеп үскән. Аның иҗатына татар көйләренең йогынтысы зур булган. Җырчы Казанда беренче тапкыр сәхнәгә чыккан һәм үзенең туган шәһәрен һәрвакыт хөрмәт белән искә алган. Дөньякүләм танылу алганнан соң да, җырчы Казан турында җир йөзендәге иң матур шәһәр дип язган.

Татарстанда ел саен Фёдор Шаляпин исемендәге опера фестивале уза, ә 13 февральдә татарстанлылар җырчының туган көнен билгеләп үтә, Казандагы һәйкәленә чәчәкләр китерә.



Фёдор Иванович Шаляпин – великий русский оперный певец. Своим талантом оказал большое влияние на мировое оперное искусство. Талант артиста раскрылся в нём в раннем возрасте. Фёдор Шаляпин родился в Казани в небогатой семье и с детства слышал татарские напевы, мелодика которых повлияла на его творчество. В Казани певец впервые вышел на сцену и всегда с любовью вспоминал о своей родине. Став всемирно известным и прославленным певцом, он писал о Казани как о прекраснейшем городе в мире.

В Татарстане каждый год проходит оперный фестиваль, который носит имя Фёдора Шаляпина, а 13 февраля татарстанцы отмечают день рождения певца, приносят цветы к его памятнику в Казани.

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘР

Шиһабетдин Мәрҗани – татар мәгърифәтчесе, үз заманының иң бөек тарихчыларыннан берсе. Ул татарларның белемен күтәрү һәм милли үзаңын үстерү өчен бик күп эшләгән.

Шигабутдин Марджани – татарский просветитель, один из крупнейших татарских историков своего времени. Он многое сделал для повышения образования татар и воспитания национального самосознания.

Абдулла Алиш – татар язучысы, балалар өчен язылган хикәя, шигырь һәм әкиятләр авторы. Бөек Ватан сугышы башлангач, фронтка киткән, үзенең халкын һәм Ватанын саклап һәлак булган. Алиш әсәрләрен берничә буын укучы белә һәм яратып укый.

Абдулла Алиш – татарский писатель, автор рассказов, стихов и сказок для детей. С началом Великой Отечественной войны ушёл на фронт, погиб, защищая свой народ и свою Родину. Произведения Алиша знает и любит не одно поколение читателей.

Алишның «Бикбатыр белән Биккуркак» әкияте геройлары

Герои сказки Алиша «Бикбатыр и Биккуркак»

Алишның «Бал корты һәм Шөпшә» әкияте геройлары

Герои сказки Алиша «Пчела и Оса»

Пётр Петрович Хузангай – чуваш шагыйре һәм тәрҗемәчесе. Хузангайның шигырьләре илебез һәм дөнья әдәбиятының алтын фондына кергән һәм 25 телгә тәрҗемә ителгән. Шагыйрь халыклар арасындагы дуслык һәм үзара ихтирамга дан җырлый.

Пётр Петрович Хузангай – чувашский поэт и переводчик. Стихи Хузангая вошли в золотой фонд отечественной и мировой литературы и переведены на 25 языков. Поэт воспевал дружбу и взаимоуважение между народами.

Андриян Григорьевич Николаев – дөньядагы беренче космонавтларның берсе. Андриян Николаев космик корабльдә, беренчеләрдән булып, скафандрсыз эшли башлаган, шулай ук беренче фәнни-техник тәҗрибәләрдә катнашкан.

Андриян Григорьевич Николаев – один из первых космонавтов в мире. Андриян Николаев первым стал работать в космическом корабле без скафандра, а также участвовал в первых научно-технических экспериментах.

Флор Иванович Васильев – удмурт совет шагыйре, удмурт телендә чыккан 7 шигырьләр җыентыгы авторы, аларның күбесе дөньяның төрле телләренә тәрҗемә ителгән.

Флор Иванович Васильев – советский удмуртский поэт, автор 7 сборников стихов на удмуртском языке, многие из которых переведены на разные языки мира.

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘР

Ашальчи Оки (Акилина Григорьевна Векшина) – беренче удмурт шагыйрәсе һәм хатын-кыз язучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны, фронт табибы. «Сугышчан хезмәтләре өчен», «Берлинны алган өчен», «Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән. Үзенең шигырьләрендә шагыйрә удмурт хатын-кызына, аның сабыр холкына һәм күңел байлыгына дан җырлый.

Ашальчи Оки (Акилина Григорьевна Векшина) – первая удмуртская поэтесса и писательница, участник Великой Отечественной войны, фронтовой врач. Награждена медалями «За боевые заслуги», «За взятие Берлина», «За победу над Германией». В своих стихах поэтесса воспевала удмуртскую женщину, её кроткий характер и духовное богатство.

Михаил Петрович Девятаев – мордва (мукшы), гвардия өлкән лейтенанты, Советлар Союзы Герое, бомбардировщикта немец концлагереннан качуны оештырган кыю очучы. Аның батырлыгы турында 2021 елда «Девятаев» фильмы төшерелде.

Михаил Петрович Девятаев – мордвин (мокша), гвардии старший лейтенант, Герой Советского Союза, знаменитый лётчик-истребитель, который смог совершить побег из немецкого концлагеря на бомбардировщике. На основе его подвига в 2021 году был снят российский фильм «Девятаев».

Степан Дмитриевич Эрьзя – мордва (эрзя) совет рәссамы, скульптура остасы. Монументаль скульптуралар иҗат итеп, дөньякүләм танылу алган.

Степан Дмитриевич Эрьзя – мордовский (эрзя) советский художник, мастер скульптуры. Завоевал мировое признание благодаря созданию монументальных скульптур.

Сергей Григорьевич Чавайн – мари шагыйре, тәрҗемәче һәм драматург, мари әдәбиятына нигез салучыларның берсе.

Сергей Григорьевич Чавайн – марийский поэт, переводчик и драматург. Один из основоположников марийской литературы.

Яков Андреевич Эшпай – мари композиторы, оркестр өчен беренче мари инструменталь әсәрләре иҗат итүче. 500 дән артык халык көен язып алган һәм эшкәрткән.

Яков Андреевич Эшпай – марийский композитор, создатель первых марийских инструментальных произведений для оркестров. Записал и обработал более 500 народных сочинений.

ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ
ҺӘМ УЕННАРЫ

Халык бәйрәмнәре һәм уеннары

Халык бәйрәмнәре һәр халыкның мәдәниятендә зур урын алып тора.

Бәйрәмнәр кешеләрне берләштерә. Бәйрәм традицияләрен саклау мәдәни мирасны буыннан буынга тапшырырга ярдәм итә. Бәйрәмнәр вакытында кешеләр халык җырларын җырлауда, милли музыка уен коралларында уйнауда, халык биюләрен биюдә үз талантларын ача ала, халык уеннары һәм күңел ачуларында катнашып, өлгерлек һәм зирәклекләрен күрсәтә.

Халык бәйрәмнәрендә кеше туган халкы белән бердәмлекне, үз милли мәдәнияте һәм традицияләренә якынлыгын тоя.

Һәр халык үз традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән аерылып тора. Татарстан халыкларында нинди бәйрәмнәр бар, алар кай яклары белән бер-берсеннән аерыла, кай яклары белән охшаш – шул турыда белик.

Народные праздники и игры

Народные праздники занимают огромное место в культуре любого народа.

Праздники объединяют людей. Соблюдение праздничных традиций помогает сохранять и передавать культурное наследие из поколения в поколение. Во время праздников люди могут проявить свои таланты в пении народных песен, игре на национальных музыкальных инструментах, умении танцевать народные танцы, показать удаль и смекалку в народных играх и забавах.

На народном празднике люди чувствуют единство со своим народом, причастность к своей национальной культуре и традициям.

Праздники одного народа отличаются от праздников других народов своими традициями, обрядами, обычаями. Но есть в них и много сходства. Давайте узнаем, какие праздники есть у народов Татарстана, чем они отличаются, а в чём их сходство.

РУС ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Рус халкы бай бәйрәм традицияләре белән дан тота. Күп гасырлар элек кешеләр язны каршылауны, кышны озатуны, уңыш җыя башлауны һәм башка мөһим вакыйгаларны мул табыннар һәм күңел ачулар белән билгеләп үткән.

Безнең көннәрдә өлкән буыннан яшь буынга тапшырыла килгән бу традицияләрне халык олылый һәм саклый.

Рус халкының күп бәйрәмнәре арасыннан бигрәк тә Май чабу, Иван Купала, Покров көне һәм, әлбәттә, Каравон яратып бәйрәм ителә.

РУССКИЕ НАРОДНЫЕ ПРАЗДНИКИ

Русский народ славится богатыми праздничными традициями. Ещё много веков назад люди отмечали пышными застольями и гуляниями встречу весны, проводы зимы, начало сбора урожая и другие важные события.

В наши дни эти традиции чтут и хранят, передавая от старшего поколения к младшему.

Среди множества праздников особенно известными и любимыми у русского народа являются весёлая Масленица, Иван Купала, Покров день и, конечно, Каравон.

Бер генә бәйрәм дә традицион рус музыка уен кораллары – **балалайка**, **гөслә**, **гармунда** уйнаган көйләрдән, аларга кушылып җырланган җырлардан башка узмаган.

Ни один праздник не обходился без песен и музыки, которую играли на **балалайках**, **гуслях** и **гармони** – традиционных русских народных музыкальных инструментах.

МАЙ ЧАБУ

Май чабу – иң борынгы халык бәйрәмнәренең берсе. Кышны озату, көтеп алынган язны һәм кояшны каршы алу чана шуу, күңелле уеннар һәм әйлән-бәйлән белән билгеләп үтелгән.

Формасы белән кояшны хәтерләткән белен бәйрәм символы булган.

Бәйрәмнең төп вакыйгасы – Май чабу карачкысын яндыру. Аның белән бергә барлык күңелсезлекләр дә янып бетә, дип санаганнар.

МАСЛЕНИЦА

Масленица – один из самых древних народных праздников. Проводы зимы и встреча долгожданной весны и солнца отмечались катаниями на санках, весёлыми играми и хороводами.

Символом праздника были блины, которые по форме напоминали солнце.

Главным событием праздника было сжигание чучела Масленицы. Считалось, что вместе с ним сгорают и все неприятности.



Күңелле Май чабу бәйрәмен руслар гына түгел, чувашлар да, удмуртлар һәм марилар да билгеләп үтә.

Весёлую Масленицу празднуют не только русские, но и чуваши, удмурты и марийцы.

КАРАВОН

Каравон рус халык бәйрәме кояш хәрәкәтен символлаштыра торган зур әйлән-бәйләннәре, ярминкәләре, бәйрәм сые тулы мул табыннары белән атаклы. Әйлән-бәйләндә үзенчәлекле «үрдәк» адымы белән йөргәннәр.

КАРАВОН

Русский народный праздник Каравон знаменит широким застольем с праздничными угощениями, ярмарками и большими хороводами, которые символизируют движение солнца. Хороводы водят особым «утиным» шагом.

ПОКРОВ КӨНЕ

Покров көне – русларның, көзге кыр эшләре тәмамланып, кышны каршы алуны аңлаткан иң мөһим бәйрәмнәреннән берсе. 14 октябрьдә билгеләп үтелә. «Покров нинди – кыш та шундый», дигәннәр халыкта. Яуган кар җирне язга чаклы каплап тора дип саналган. Бәйрәмнең исеме дә шуннан килеп чыккан.

ПОКРОВ ДЕНЬ

Покров день – один из самых важных русских праздников, обозначающий завершение осенних работ в поле и встречу зимы. Отмечается 14 октября. В народе примечали: «Каков Покров – такова и зима». Считалось, что выпавший снег покрывал землю до самой весны. Отсюда и название праздника.

ИВАН КУПАЛА

Иван Купала елның иң кыска төне – 6 июльдән 7 сенә каршы төндә үткәрелгән. Бәйрәм вакытында яшьләр учак аркылы сикергән, җырлар җырлаган, әйлән-бәйлән уйнаган. Кызлар такыялар үргән һәм, аларны суга төшереп, киләчәкне юраган. Иван Купалада мунчага барганнар, елга яки күлдә коенганнар, шулай итеп, халык ышанулары буенча, бөтен начарлыктан чистарынганнар.

ИВАН КУПАЛА

Иван Купала отмечается в ночь с 6 на 7 июля – самую короткую ночь года. Во время праздника молодёжь прыгала через костры, пела песни, водила хороводы. Девушки плели венки и гадали, опуская их на воду. На Ивана Купалу ходили в баню, купались в реке или озере, тем самым, по народным поверьям, очищаясь от всего плохого.

«Инеш» рус халык уены

Борынгы заманнардан ук билгеле. Парлар (гадәттә, егет белән кыз) тотынышкан килеш кулларын өскә күтәрәләр һәм бер-бер артлы басалар. Кемгә пар эләкмәгән, шул «инеш»нең уртасыннан бара һәм, үзенә пар сайлап, «инеш»нең башланган урынына баса. Парсыз калганы янәдән, «инеш» эченнән барып, үзенә пар сайлый һәм «инеш» башланган урынга бара. Катнашучыларның саны күбрәк булган саен, уен күңеллерәк бара.

Русская народная игра «Ручеёк»

Известна с древних времён. Пары (обычно парень с девушкой) держатся за руки, поднимая их высоко над головой, и встают друг за другом. Тот, кому пара не досталась, идёт внутри «ручейка» и, выбрав себе пару, встаёт к «истоку» – в начало «ручейка». Оставшийся без пары идёт внутри «ручейка» и снова, выбрав себе пару, идёт к «истоку». Чем больше участников, тем веселее игра.

ТАТАР ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Күпмилләтле Татарстанда төрле халыкларның бәйрәмнәре зур колач белән билгеләп үтелә. Алар арасында барлык халыклар катнашында күңелле итеп үткәрелә торганнары да бар. Шундый бәйрәмнәрнең берсе – Сабантуй.

ТАТАРСКИЕ НАРОДНЫЕ ПРАЗДНИКИ

В многонациональном Татарстане с большим размахом отмечаются праздники разных народов. Но есть среди них такие, которые весело и дружно отмечаются всеми народами. Один из них – Сабантуй.

САБАНТУЙ

Сабантуй – татар халкының иң матур бәйрәме. Аны язгы кыр эшләре беткән хөрмәткә июнь аенда билгеләп үтәләр. Ул күңелле уеннары һәм бәйгеләре, халык күңел ачулары һәм җыр-биюләре белән төрле милләт кешеләрен үзенә тарта, шунлыктан бөтен дөньяга билгеле.

Ат чабышы һәм татарча көрәш традицион рәвештә Сабан туеның төп вакыйгасы санала. Җиңүче батыр төп бүләк – тәкә һәм иң матур сөлгене ала.

САБАНТУЙ

Сабантуй – самый яркий праздник татарского народа. Его отмечают в июне в честь окончания весенних полевых работ. Весёлыми играми и конкурсами, народными гуляниями и танцами привлекает он людей разных национальностей, а потому известен во всём мире.

Главными событиями Сабантуя традиционно считаются скачки на лошадях и состязания борцов татарской народной борьбы на поясах – курэш. Победитель, батыр, получает главный приз – барана, и самое красивое полотенце.

ҖЫЕН

Җыен – татарларның иң борынгы бәйрәмнәреннән берсе. Аны җәй көне, печән өсте башланыр алдыннан үткәргәннәр. Бәйрәм көннәрендә ярминкәләр оештырылган, авыл халкы бер-берсенә кунакка йөрешкән. Кунакларны кырда, чәчәкләр һәм тасмалар белән бизәлгән капка янында, сый белән каршы алганнар. Ә кичен барлык кеше өчен табын әзерләгәннәр.

ЖИЕН

Жиен (в переводе с татарского языка «встреча, сбор») – один из самых древних праздников татар. Его отмечали летом, перед началом сенокоса. В дни празднования устраивались ярмарки, жители деревень ездили друг к другу в гости. Встречали гостей угощениями около украшенных цветами и лентами ворот в поле. А вечером накрывали для всех богатый праздничными блюдами стол.

«Чүлмәк вату» татар халык уены

Сабан туенда һәм башка бәйрәмнәр вакытында олысы да, кечесе дә «Аркан тарту», «Капчык киеп йөгерү», «Баганага менү», «Көянтә белән йөгерү» кебек кызыклы уеннар уйныйлар. Иң күңеллеләреннән берсе – «Чүлмәк вату». Күзләре бәйләнгән катнашучы таяк белән балчык чүлмәкне ватарга тиеш, ә тамашачылар катнашучыга сугу өчен юнәлешне әйтеп торалар.

Татарская народня игра «Разбивание горшка»

На Сабантуе и во время других праздников стар и млад играют в весёлые игры, которых известно великое множество: «Перетягивание каната», «Бег в мешках», «Столб», «Бег с коромыслом». Одна из самых весёлых – «Разбивание горшка» («Чүлмәк вату»). Участникам с завязанными глазами нужно палкой разбить глиняный горшок, а зрители подсказывают участникам направление для удара.

КАРГА БОТКАСЫ

Карга боткасы – язны каршы алу бәйрәме. Борынгы чорларда кешеләр язны канат очларында кара каргалар алып килә дип ышанганнар. Барлык кешегә дә җитсен дип, ботканы зур казанда пешергәннәр. Беренче порцияне, яхшы уңыш булсын дигән теләк белән, җиргә биргәннәр. Икенче өлешне корылык булмасын дип – елгага, өченчесен җылыны өмет итеп – күккә, ә дүртенчесен, язны алып килгән өчен, рәхмәт йөзеннән каргаларга биргәннәр.

КАРГА БОТКАСЫ

Карга боткасы (в переводе с татарского языка «грачиная каша») – праздник встречи весны. В древние времена люди верили, что весну приносят грачи на кончиках крыльев. Кашу варили в большом казане, чтобы угощения хватило всем. Первую порцию каши отдавали земле с просьбой о хорошем урожае. Вторую порцию – реке, чтобы не было засухи. Третью – небу с надеждой на тепло, а четвёртую – грачам в благодарность за принесённую весну.

Музыкасыз нинди бәйрәм инде ул! Татарлар – җырлы-моңлы халык. Татарларның традицион көйләрен башка халыкларның музыкасы белән бутап булмый. Татар көйләре кабатланмас моңы, күңелгә үтеп керә торган аһәңе һәм үзенчәлекле милли яңгырашы белән аерылып тора.

Какой же праздник без музыки! Татары – музыкальный народ. Традиционные татарские мелодии не спутать с музыкой других народов. Татарская музыка отличается неповторимой мелодичностью, душевностью, красотой и особым национальным колоритом.

КАЗ ӨМӘСЕ

Каз өмәсе татарларның кышкы йолалары арасында аерым урынны алып торган. Күршеләр, кызлар һәм егетләр, берәр нинди эшне өмә белән башкару өчен, бергә җыелганнар. Мәсәлән, бергәләп казлар йолкыганнар һәм шул вакытта аралашканнар.

КАЗ ОМЭСЕ

Каз омэсе (в переводе с татарского языка «гусиное перо») занимал особое место в зимних обрядах татар. Соседи, девушки и парни, собирались вместе, чтобы помочь выполнить какую-нибудь работу. Например, вместе ощипывали гусей и при этом общались.

Традицион татар музыка уен кораллары – **курай**, **тальян гармун** һәм **кубыз.**

Традиционные татарские музыкальные инструменты – **курай**, **гармонь-тальянка** и **кубыз.**

ПИТРАУ

Питрау – традиция буенча җәй уртасында үткәрелә торган керәшен (татарлар составындагы этник төркем) бәйрәме. Питрауга җиләкләр һәм үләннәр җыю гадәте булган. Кешеләр, әгәр дә кырык үләннән торган себерке белән чабынсаң, теләсә кайсы авыруны җиңеп була, дип ышанган. Кичен җырлар җырлаганнар һәм учак аша сикергәннәр.

ПИТРАУ

Питрау – древний праздник кряшен (этническая группа в составе татар), который по традиции отмечают в середине лета. На Питрау было принято собирать ягоды и травы. Люди верили, что, если попариться веником из сорока разных трав, можно вылечить любую болезнь. Вечером пели песни и прыгали через костры.

ЧУВАШ ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Чувашлар үз традицияләрен саклыйлар һәм матур итеп милли бәйрәмнәрен үткәрәләр.

Саварни (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «май атнасы») яз башында билгеләп үтелә. Бәйрәмгә белен, йомры күмәч, йава – йола печеньесы пешергәннәр, бер-берләренә бүләкләр бирешкәннәр, белен белән сыйланганнар, атта җырлап йөргәннәр, күңел ачканнар. Бәйрәм ахырында карачкыны яндырганнар.

ЧУВАШСКИЕ НАРОДНЫЕ ПРАЗДНИКИ

Чуваши бережно хранят свои традиции и всегда дружно отмечают национальные праздники.

Саварни (в переводе с чувашского языка «масляная неделя») отмечается в начале весны. На праздник пекли блины, колобки и обрядовое печенье йава, дарили друг другу подарки, угощали блинами, с песнями и музыкой катались на лошадях, веселились. В конце празднования сжигали чучело – масляничную бабу.

Чуваш гөсләсе – **кесле** һәм чуваш сыбызгысы – **шахлич** күңелле милли бәйрәмнәрнең юлдашы булган.

Постоянными спутниками весёлых праздников чувашей были **кесле** – чувашские гусли, и **шахлич** – чувашская свирель.

АКАТУЙ

Акатуй (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «сабан туе») – чуваш халкының язгы кыр эшләре бетүгә багышланган иң мөһим милли бәйрәмнәренең берсе. Бу көнне чувашлар бер-берсен җәй килү белән котлаган, әйлән-бәйлән оештырган, халык җырлары җырлаган. Хатын-кызлар милли сыйлар – чакат (эремчек запеканкасы) һәм шурпа (милли аш) пешергән. Ирләр билбаулы көрәш, ат чабышы, көч һәм җитезлек сорый торган башка спорт уеннары оештырган.

Чакат һәм шурпа
Запеканка чакат и суп шурпе

АКАТУЙ

Акатуй (в переводе с чувашского языка «свадьба плуга») – один из самых важных национальных праздников чувашского народа, посвящённый окончанию весенне-полевых работ. В этот день чуваши поздравляли друг друга с приходом лета, водили хоровод, пели народные песни. Женщины готовили традиционные угощения – творожную запеканку чакат и национальный суп шурпе. Мужчины устраивали спортивные соревнования: керешу (борьба на поясах), скачки и другие состязания в ловкости и силе.

ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ
ҺӘМ УЕННАРЫ

УЯВ

Уяв (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «саклау») – чувашларның борынгы бәйрәмнәре. Ул печән өстенә кадәр берничә атна дәвам иткән. Бәйрәм исеме аралашу, чуваш халкының бердәмлеге, халык традицияләрен саклау белән бәйле. Бу көннәрдә кешеләр, уңыш булсын дип, дога кылганнар, яшьләр учак тирәли әйлән-бәйлән оештырганнар, җырлар җырлаганнар, халык уеннары уйнаганнар, Уяв чибәрен сайлаганнар.

УЯВ

Уяв (в переводе с чувашского языка «соблюдение») – древний праздник чувашей. Он длился несколько недель до начала сенокоса. Название праздника связано с общением, единением чувашского народа, соблюдением народных традиций. В эти дни люди молились об урожае, молодёжь водила широкие хороводы вокруг костра, пела песни, играла в народные игры, выбирала красу Уява.

СУРХУРИ

Сурхури (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «сарык аягы») – декабрь ахырында үткәрелә торган борынгы бәйрәм. Бәйрәм атнасында чувашлар, уңыш яхшы булсын дип, йолалар башкарганнар, кунакка йөрешкәннәр, бәйрәм ашы белән сыйланганнар, җырлар җырлаганнар, бер-берсен бәйрәм белән котлаганнар.

СУРХУРИ

Сурхури (в переводе с чувашского языка «овечья нога») – старинный праздник, отмечался в конце декабря. Во время праздничной недели чуваши совершали обряды для хорошего урожая, ходили в гости, угощались праздничными кушаньями, пели песни, поздравляли друг друга с праздником.

«Сезгә кем?» («Тили-рам?») чуваш халык уены

Ике команда 10–15 метр ара белән берберсенә кара-каршы баса. Беренче команда хор белән: «Тили-рам, тили-рам» («Сезгә кем? Сезгә кем?»), – ди. Икенче команда беренче командадагы бер уенчыны атый, ул, йөгереп килеп, икенче команданың кысып тоткан кулларын өзәргә тиеш.

Әгәр йөгереп килүче икенче команданың чылбырын өзсә, ул үз командасына бер уенчыны алып китә. Әгәр йөгерүче чылбырны өзә алмаса, ул дошман командасында кала. Аннары командалар рольләрне алмашалар. Җиңүче команда канат тартканнан соң билгеләнә.

Чувашская народная игра «Кого вам?» («Тили-рам?»)

Две команды встают друг напротив друга на расстоянии 10–15 метров. Первая команда говорит хором: «Тили-рам, тили-рам?» («Кого вам, кого вам?»). Другая команда называет одного игрока из первой команды, который должен подбежать и прорвать сцепленные руки второй команды.

Если бегущий прорвал цепь другой команды, он уводит в свою команду одного игрока. Если бегущий не прорвал цепь, он остаётся в команде противника. Затем команды меняются ролями. Команда-победитель определяется после перетягивания каната.

УДМУРТ ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Башка халыклардагы кебек үк, удмуртларның бәйрәмнәре дә һәрвакыт кечесен дә, олысын да бергә җыйган. Бәйрәмнәрдә матур итеп киенү, милли ризыклар әзерләү, күңел ачу, бер-береңә яхшылык теләү кабул ителгән була.

УДМУРТСКИЕ НАРОДНЫЕ ПРАЗДНИКИ

Праздники у удмуртов, как и у других народов, всегда собирали всех – от мала до велика. На праздники принято было особенно нарядно одеваться, готовить национальные блюда, веселиться и желать друг другу добра.

ВОЙ (ВОЙДЫР)

Вой (Войдыр) – кышны озату. Бәйрәм русларның Май чабу бәйрәменә охшаган: һәрбер өйдә кояш символы булган белен пешергәннәр, аның белән кунакларны сыйлаганнар, үзләре дә ашаганнар. Войдыр вакытында мул ярминкәләр оештырылган, чана шуганнар, җырлаганнар һәм биегәннәр. Ә бәйрәмнең төп вакыйгасы карачкы яндыру булган.

ВОЙ (ВОЙДЫР)

Вой (Войдыр) – проводы зимы. Праздник похож на русскую Масленицу: в каждом доме пекли блины – символ солнца, угощали ими гостей и ели сами. На Войдыр устраивались богатые ярмарки, катались на санях, пели и плясали. А главным событием праздника было сжигание чучела.

Бәйрәмнәрдә һәрвакыт милли музыка уен кораллары яңгыраган.
Крезь (удмурт теленнән тәрҗемә иткәндә «җыр, моң») – рус гөсләсенең «туганы», кыллы, чиртеп уйный торган халык музыка уен коралы.
Ә удмурт скрипкасы – **кубыздан** башка бер генә туй да үтмәгән.

На праздниках всегда звучат национальные музыкальные инструменты.
Крезь (в переводе с удмуртского языка «песня, напев») – народный струнный щипковый музыкальный инструмент, «родственник» русских гуслей.
А без удмуртской скрипки **кубыз** не обходилась ни одна свадьба.

БЫДЗЫМНУНАЛ

Быдӟымнунал (башка исемнәре: Буӟӟиннал, Великтэм, Акашка, Паска) – удмурт Пасхасы. Төп бәйрәм көнендә, кояш чыкканнан соң, пасха ашы – шыд, табани (юка көлчәләр), ипи пешергәннәр. Аларны изгеләндергәннәр, дога кылганнар, ә аннары табын артына утырганнар. Йорт хуҗасы өстәл янында утырган балаларга түгәрәк буйлап буялган йомырка җибәргән. Пасханың иң күңелле мизгеле йомырка вату булган: үзе бөтен калып, башканыкын ваткан йомырка хуҗасы пасха йомыркасы алган.

БЫДЗЫМНУНАЛ

Быдӟымнунал (другие названия: Буӟӟиннал, Великтэм, Акашка, Паска) – удмуртская Пасха. После восхода солнца в главный день праздника варили пасхальный суп паскашыд, пекли табани (тонкие лепёшки), хлеб. Их освящали, молились, а затем садились за стол. Хозяин дома пускал крашеное яйцо по кругу сидящих за столом детей. Пасхальной забавой было разбивание яиц: тот, чьё яйцо останется целым и разобьёт другое, выигрывал пасхальное яйцо.

ГЫРОН БЫДТОН

Гырон быдтон (удмурт теленнән тәрҗемә иткәндә «сабан эше тәмамлану») – Татарстандагы иң танылган һәм халык күп җыела торган удмурт бәйрәме. Борынгы заманнарда ул уңыш әйбәт булсын өчен дога кылу һәм җиргә корбан китерүдән башланган, бәйрәм күңел ачулар белән дәвам иткән. Традиция буенча, бәйрәм кунакларын учакта пешкән ботка белән сыйлаганнар. Бөтен җирдә җырлар җырлаганнар, биегәннәр, яшьләр халык күңел ачулары вакытында кызыклы уен һәм бәйгеләрдә көч һәм җитезлек буенча ярышкан.

ГЫРОН БЫДТОН

Гырон быдтон (в переводе с удмуртского языка «завершение пахоты») – самый известный и многолюдный удмуртский праздник в Татарстане.

В старину он начинался с молений и жертвоприношений земле для хорошего урожая и продолжался праздничными гуляниями.

Гостей праздника по традиции угощают кашей, сваренной на костре. Повсюду пели песни, танцевали, молодёжь мерилась силой и ловкостью во время народных забав – весёлых игр и конкурсов.

ВОЖОДЫР

Вожодыр – 7 гыйнвардан 19 ына кадәр үтә торган бәйрәм. Утырмалар, күрәзәлек итү, битлек кию Вожодырның төп вакыйгалары булган. Битлек кигән кешеләр ишегалларына кереп җырлап йөргән. Йорт хуҗалары аларны тәм-томнар һәм бәлеш белән сыйлаган. Битлек кигән кешеләр бәхет һәм сәламәтлек китерә, дип уйлаганнар.

ВОЖОДЫР

Вожодыр – зимний праздник, который проходил с 7 по 19 января. Главными событиями Вожодыра были посиделки, ряженье и гадание. Ряженые ходили по дворам, пели песни. Хозяева угощали их пирогами, сладостями. Считалось, что ряженые приносят счастье и здоровье.

«Кубыста йыр» («Кәбестә кәчәне») удмурт халык уены

Санамыш ярдәмендә ике алып баручыны билгелиләр: Каравылчы һәм Кәбестә. Уенчылар алып баручылардан 2–3 адым ераклыкта басалар. Каравылчы Кәбестәне берничә тапкыр әйләнеп йөгереп чыга да: «Кәбестә өлгерде!» – дип кычкыра. Уенчылар, йөгереп килеп, Кәбестәгә кул белән кагылырга тиешләр. Каравылчы бер кулы белән чүгәләп утырган Кәбестәнең башыннан тота, ә икенче кулы белән уенчыларга орынырга тиеш. Ул, кемгә дә булса орына алса, «Каракны тоттым!» дип кычкыра. Тотылганы – Каравылчы, ә Каравылчы Кәбестә була.

Удмуртская народная игра «Кубыста йыр» («Кочан капусты»)

По считалочке выбирают двух водящих: Сторожа и Капусту. Игроки встают на расстоянии 2–3 шагов от ведущих. Сторож несколько раз обегает Капусту и кричит: «Капуста поспела!» Игроки должны подбежать и дотронуться до Капусты рукой. Сторож одной рукой держит голову сидящей на корточках Капусты, а другой должен запятнать игроков. Запятнав кого-нибудь, он кричит: «Поймал вора!» Пойманный становится Сторожем, а Сторож – Капустой.

МОРДВА ХАЛЫКЛАРЫ БӘЙРӘМНӘРЕ

Мордва халык бәйрәмнәре тирән тарихи тамырларга ия. Тантаналар, уңыш җыйганнан соң, язны каршы алганда һәм кешеләр тормышындагы башка мөһим вакыйгалар уңаеннан үткәрелгән. Һәрбер бәйрәмне билгеле бер йолалар озата килә. Халыкның мәдәниятен, милли үзенчәлекләрен саклау өчен, бәйрәм традицияләрен үтәү, аларның мәгънәсен белү бик мөһим.

ПРАЗДНИКИ НАРОДОВ МОРДВЫ

Народные праздники мордвы имеют глубокие исторические корни. Торжества устраивались после сбора урожая, с приходом весны и по другим важным событиям в жизни людей. Каждый праздник сопровождают определённые обряды, ритуалы. Соблюдение народных праздничных традиций, знание их смысла очень важно для сохранения национальной самобытности и культуры народа.

МАСЛАНЦЯ (МУКШЫ), ЯКИ МАСТЯ (ЭРЗЯ)

Масланця (мукшы), яки Мастя (эрзя) рус Май чабу бәйрәменә охшаш. Халыкта: «Май чабу бәйрәмен ничек каршылыйсың – елың шулай үтә», – дигәннәр. Шуңа күрә язны каршы алу бәйрәме һәрчак биюләр, Май чабу тавыннан чаналарда шуу һәм, әлбәттә, тәмле белен белән сыйланып, шау-шулы һәм күңелле үткән.

МАСЛАНЦЯ (МОКША), ИЛИ МАСТЯ (ЭРЗЯ)

Масланця (мокша), или Мастя (эрзя), похожа на русскую Масленицу. В народе говорили: «Как встретишь Масленицу, таков и весь год». Поэтому праздник встречи весны всегда проходил шумно и весело, с плясками, катанием на санках с Масленичной горы и, конечно, с вкусными блинами.

ОЧИЖИ (МУКШЫ), ЯКИ ИНЕЧИ (ЭРЗЯ)

Очижи (мукшы), яки Инечи (эрзя) (тәрҗемәдә «Бөек көн») – мордва Пасхасы. Бәйрәмгә алдан әзерләнгәннәр. Төп сый: кургине – эремчек яки бәрәңге салынган зур ватрушка, кулич, эремчекле пасха, тормыш һәм аның яңарышы символы – буялган йомырка.

Пасханы гәүдәләндереп, бәйрәмчә киенгән пар – егет белән кыз йортлар буйлап йөргән. Һәр йортта аларны шатлык белән каршы алганнар һәм сыйлаганнар, кучтәнәч биргәннәр.

ОЧИЖИ (МОКША), ИЛИ ИНЕЧИ (ЭРЗЯ)

Очижи (мокша), или Инечи (эрзя) (в переводе «Великий день») – мордовская Пасха. К празднику готовились заранее. Главные угощения: кургине – большие ватрушки с творогом или картошкой, куличи, творожная пасха и крашеные яйца как символ жизни и её возрождения.

По дворам ходила пара – празднично одетые парень и девушка, олицетворявшие Пасху. В каждом доме их встречали с радостью и одаривали угощениями.

Бәйрәмнәрдә аска таба киңәеп киткән тар тактага охшаган, кылы астында үгез куыгы булган халык музыка уен коралы – **гайтияма** (мукшы), яки **гайдяма** (эрзя) тавышы астында йола җырлары җырланган.

Праздники сопровождались обрядовыми песнями, которые пели под звуки **гайтиямы** (мокша), или **гайдямы** (эрзя) – народного музыкального инструмента, который похож на узкую, расширяющуюся книзу дощечку с бычьим пузырём под струной.

БАЛТАЙ

Балтай – мордваларның урман хуҗасы – аюга багышланган борынгы бәйрәмнәре. Бәйрәмнең төп геройлары – өрәңге яфраклары белән бизәлгән берничә кешедән торган «аю гаиләсе». Алар авыл буйлап йөри һәм һәрбер кешегә тынычлык һәм яхшылык тели.

Бәйрәмгә кешеләр бөтен республикадан килә, халык бергәләп бии, җырлар җырлый һәм милли уеннар уйный.

БАЛТАЙ

Балтай – древний праздник народов мордвы, посвящённый хозяину леса – медведю. Главные герои праздника – «медвежья семья», которую изображают несколько человек, наряженных в кленовые листья. Они ходят по деревне и желают каждому дому добра и мира.

На праздник приезжают люди со всей республики, вместе танцуют, поют народные песни и играют в народные игры.

РОШТУВАНЬ КУД (МУКШЫ), ЯКИ РОШТОВАНЬ КУДО (ЭРЗЯ)

Роштувань куд (мукшы), яки Роштовань кудо (эрзя). Бәйрәмнең исеме тәрҗемәдә «Раштуа ызбасы» дигәнне аңлата. Тантана 25 декабрьдән 7 гыйнварга кадәр сузылган. Аны колядкалар, бер-берсенә яхшылык һәм муллык теләгән йола җырлары, биюләр белән билгеләп үткәннәр. Кулларны өскә күтәреп бию кабул ителгән була, ул кояшка мөрәҗәгатьне һәм агачны символлаштырган. Бодай, арыш, карабодай көлтәләренә карап, уңышны фаразлаганнар: кайсы көлтәдә төне буена бәс күбрәк була, яңа елда шул ашлык уңачак.

РОШТУВАНЬКУД (МОКША), ИЛИ РОШТОВАНЬКУДО (ЭРЗЯ)

Роштуванькуд (мокша), или Роштованькудо (эрзя). Название праздника в переводе означает «Рождественская изба». Торжество длилось с 25 декабря по 7 января. Отмечали его колядками, пением обрядовых песен, в которых желали друг другу добра и достатка, и танцами. Плясать принято было с поднятыми вверх руками, символизировавшими дерево и обращение к Солнцу. По снопам пшеницы, ржи, гречихи гадали об урожае: на каком снопе за ночь будет больше инея, такой злак и уродится в новом году.

«Ачкыч» мордва уены

Мордва халык уены «Ачкыч» («Пантемаса» (мукшы), «Панжомнесэ» (эрзя)). Җиргә сызып ясалган квадрат эчендәге алып баручы, почмакларда утыручы уенчыларның берсе янына килеп: «Абый, (апа), ачкыч синдәме?» – дип сорарга тиеш. Тегесе, күршесенә күрсәтеп: «Әнә абыйдан (ападан) сора», – дип җавап бирә. Шул рәвешле алып баручы дүртесен дә әйләнеп чыга. Соңгы кеше: «Уртадан эзлә!» – дип, аны квадрат уртасына җибәрә. Бу вакытта уенчылар тиз генә урыннарын алмашырга тиешләр, ә алып баручы кемнеңдер урынын алырга тырышырга тиеш. Урынсыз калган кеше уенны алып бара.

Мордовская игра «В ключи»

Мордовская народная игра «В ключи» («Пантемаса» (мокша), «Панжомнесэ» (эрзя)). Водящий, который стоит в середине начерченного на земле квадрата, должен подойти к одному из сидящих по его углам игроков и спросить: «Дядя (тётя), у тебя ключи?» Тот отвечает, указывая на соседа: «Вон у дяди (тёти) спроси». Так водящий обходит всех четверых. Последний говорит: «Посередине поищи!» и отправляет его в центр квадрата. В это время игроки должны быстро поменяться местами, а водящий постараться занять чьё-нибудь место. Оставшийся без места водит.

МАРИ ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Уярня (Май чабу) – мариларның борынгы бәйрәме.

Бәйрәм алдыннан өйне яхшылап җыештырганнар, бәйрәм киемнәрен әзерләгәннәр, атны һәм арбаны тасмалар белән бизәгәннәр. Хуҗабикәләр белен пешергән, ә яшьләр бәйрәм тавы (Уярна вара) төзегән.

Уярня курык – таудан шуу кызыклы күңел ачу гына булмаган. Никадәр ераккарак шуып китә аласың, киндерең шуның кадәр озынрак һәм ныграк булып уңачак, дип санаганнар.

МАРИЙСКИЕ НАРОДНЫЕ ПРАЗДНИКИ

Уярня (Масленица) – древний праздник марийцев.

Перед праздником дом тщательно прибирали, готовили праздничную одежду, украшали повозки и лошадей лентами. Хозяйки пекли блины, а молодёжь строила масляничные горы (Уярна вара).

Уярня курык – катание с горки – было не только весёлым развлечением. Считалось, что чем дальше прокатишься, тем длиннее и крепче уродится лён.

КУГЕЧЕ

Кугече (Пасха) – кышкы йокыдан уянучы табигатьне олылау бәйрәме. Бәйрәм өстәленә һәрвакыт мари милли ашамлыклары һәм буялган йомырка куелган. Бәйрәм традицияләренең берсе атынчыкта атыну булган. Легенда буенча, мари халкы әлеге атынчык буйлап җиргә төшүче Юмынудырдан килеп чыккан.

КУГЕЧЕ

Кугече (Пасха) – праздник почитания оживающей от зимнего сна природы. На праздничном столе всегда были национальные марийские блюда и крашеные яйца. Одной из праздничных традиций было катание на качелях, с которыми связана легенда о появлении марийского народа от Юмынудыр, по качелям спустившейся на землю.

«Йыдал пазар» («Чабата базары») мари уены

Уярня бәйрәмендә уйналган борынгы уен. Тузган чабаталарны җыйганнар, урталай чапканнар һәм кучкә өйгәннәр. Уртасына баулы таяк кадап куйганнар. Алып баручы бауны тоткан һәм куч тирәли йөгергән, ә калган уенчылар аннан чабаталар тотарга тиеш булган. Йөгерүче чабаталарны сакларга һәм «каракларны» тотарга тиеш. Аның тарафыннан тотылган уенчы алып баручы булган.

Марийская игра «Йыдал пазар» («Базар лаптей»)

Старинная игра, в которую играли в праздник Уярня. Изношенные лапти собирали, рубили пополам и складывали в кучу. В середину втыкали палку с верёвкой. Водящий брал верёвку и бегал вокруг кучи, а остальные игроки должны были выхватить из неё лапти. Бегающий должен охранять лапти и ловить «воришек». Пойманный им игрок становится водящим.

СЕМЫК

Семык язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрелгән һәм җәй килүгә багышланган. Бәйрәм вакытында кунакка йөрү, җырлау, яхшы уңыш сорап дога кылу, гөслә һәм сорнай тавышына бию кабул ителгән. Бүгенге көндә Семык – мөмкин булган барлык күңел ачуларга – фольклор ансамбльләре чыгышы, ярминкәләр, халык кул эшләре күргәзмәләренә бай күңелле җәйге бәйрәм.

Яшьләр милли уеннарда һәм спорт ярышларында: канат тарту, капчык сугышы, көянтә белән йөгерү, колгага менү һәм башка күңелле бәйгеләрдә катнаша.

СЕМЫК

Семык отмечался после окончания весенних полевых работ и посвящался приходу лета. Во время праздника принято ходить в гости, петь, молиться о хорошем урожае, плясать под гусли и волынки. Сегодня Семык – это весёлый летний праздник, который богат всевозможными развлечениями: выступлениями фольклорных ансамблей, ярмарками и выставками народных ремёсел.

Молодёжь участвует в национальных играх и спортивных состязаниях: перетягивании каната, боях мешками, беге с коромыслом, лазанье на шест и других весёлых конкурсах.

ШОРЫКЙОЛ

Шорыкйол (мари теленнән тәрҗемә иткәндә «сарык аягы») декабрь яки гыйнварда үткәрелгән. Бәйрәм вакытында гаиләнең иминлеге һәм яхшы уңыш өчен йолалар уздырылган. Бәйрәмнең төп йоласын кызлар һәм егетләр үткәргән. Алар, һәр хуҗалыкка кереп, сарыкларның тәпиләреннән тарткан, шуның белән йорт хайваннарына үрчем теләгән.

ШОРЫКЙОЛ

Шорыкйол (в переводе с марийского языка «овечья нога») отмечался в декабре или январе. Во время праздника проводились обряды для благополучия семьи и хорошего урожая. Главный обряд праздника совершали девушки и парни. Они ходили по дворам и дёргали овец за ноги, желая этим плодовитости домашнему скоту.

Бәйрәмдә музыкантлар аерым хөрмәткә ия булган. Алар күңелле көйләр уйнаган һәм тантананы чын мәгънәсендә матур иткән. Мариларның барлык бәйрәмнәре мари сорнае – **шувыр** авазлары астында үткән. Музыкантлар халык йолалары вакытында – матур озын көйләр, туйларда дәртле бию көйләре уйнаган.

На праздниках особым уважением пользовались музыканты. Они играли весёлые мелодии и делали торжество по-настоящему ярким. Под звуки **шувыра** – марийской волынки – проходили все праздники марийцев. Музыканты играли на нём и красивые протяжные мелодии во время народных обрядов, и задорные плясовые на свадьбах.

Милли кухня

Идел буе халыкларының кухнясы бай һәм төрле. Без белгән һәм яраткан ашамлыклар борынгыдан барлыкка килгән. Аларның рәвеше, формасы, рецептларда кулланылган продуктлар билгеле бер йолалар белән бәйле булган. Ашамлык һәм аны ашау аерым бер мәгънә белдергән. Менә, мәсәлән, белен кояшны символлаштырган, ә аны ашау тиздән җылы килүен фаразлаган, ботка муллык символы булган.

Күпчелек ризык аерым бер көннәрдә – халык бәйрәмнәрендә һәм туйларда гына әзерләнгән.

Национальная кухня

Кухня народов Поволжья богатая и разнообразная. Блюда, которые мы знаем и любим, появились в древности. Их вид, форма, использовавшиеся в рецептах продукты были связаны с определёнными ритуалами и обрядами. Блюда и их поедание имели особый сакральный смысл. Так, например, блины символизировали солнце, их поедание сулило скорейший приход тепла, а каша была символом достатка.

Многие кушанья готовились только по особым дням – в дни народных праздников и свадеб.

Рус халык кухнясы

Рус халык кухнясы беленнәре, ашлары һәм бәлешләре белән данлыклы. Озын кышларда кешеләр күп кенә кайнар һәм туклыклы ашамлыклар әзерләгән. Борынгыдан килгән рус ашамлыклары – борщ, солянка, щи гадәти көннәрдә дә, бәйрәмнәрдә дә табынга куелган. Пилмәнне берьюлы күп итеп әзерләгәннәр һәм өйалдында катырганнар.

Рус кухнясы шулай ук алдагы көннәргә дип әзерләнә торган традицион кабымлык рецептларына да бай: тозланган, киптерелгән яшелчә, җиләк-җимешләр, осетрина, койка (холодец), кара һәм кызыл уылдык.



РУССКАЯ НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ

Русская национальная кухня славится блинами, супами и пирогами. Во время долгой зимы люди готовили много горячих и сытных блюд. Знаменитые борщ, солянку, щи – исконно русские блюда – ели и в будни, и на праздники. Пельменей часто готовили сразу много и замораживали в сенях (холодном помещении перед входом в дом). Также русская кухня богата рецептами традиционных закусок, которые готовили впрок: солёных, мочёных и квашеных овощей, фруктов, осетрины, холодца, чёрной и красной икры.

Белен рецепты

Продуктлар:

4 йомырка,

4 аш кашыгы атланмай,

2 стакан сөт,

1 стакан он,

1,5 аш кашыгы шикәр комы,

тоз.



1. Йомырка сарысын атланмай белән тугларга, шуңа 1 стакан сөт, он салырга, тоз өстәп, яхшы итеп болгатырга.
2. 1 стакан сөт салып болгатырга.
3. Аерым савытта йомырка агын шикәр комы белән күпертергә һәм аны камырга салырга.
4. Камырны табага юка катлам итеп агызырга. Белен юка һәм йомшак булачак.

Рецепт блинов

Продукты:

4 яйца,

4 ст. ложки сливочного масла,

2 стак. молока,

1 стак. муки,

1,5 ст. ложки сахара,

соль.

1. Желтки растереть со сливочным маслом, влить к ним 1 стак. молока, муку, посолить и тщательно размешать.
2. Добавить 1 стакан молока, перемешать.
3. В отдельной посуде взбить белки с сахаром и влить их в тесто.
4. Выливать тесто на сковороду тонким слоем. Так блины будут тонкими и эластичными.

МИЛЛИ КУХНЯ

Рус ызбасында төп урынны мич алып торган. Аны туендыручы дип йөрткәннәр: анда төрле ашлар, бәлешләр һәм боткалар пешергәннәр. Мич өстендә салкыннан җылынганнар.

Центральное место в русской избе занимала печь. Её называли кормилицей: в ней готовили разнообразные супы, пекли пироги и варили каши. На печи согревались от холода.



ТАТАР МИЛЛИ КУХНЯСЫ

Татар милли кухнясының төрлелеге һәм байлыгы турында бөтен дөньяда беләләр.

Татар ашамлыкларыннан иң танылганнары – өчпочмаклар, пәрәмәчләр, кыстыбый, сумса, бавырсак, пироглар (өлеш, бәлеш, гөбәдия), шурпа (итле аш). Һәм, әлбәттә, татар кухнясын чәкчәк, чәлпәк, катлама, кош теле һәм башка татлы ашамлыклардан башка күз алдына да китереп булмый, алардан башка бер генә бәйрәм дә узмый.

ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ

О разнообразии и богатстве татарской национальной кухни знают во всём мире.

Самые известные татарские блюда – это эчпочмаки, перемячи, кыстыбый, сумса, баурсаки, пироги (элеш, бэлиш, губадия), шурпа (мясной суп).

И конечно, татарскую кухню невозможно представить без таких сладких блюд, как чак-чак, чельпек, катлама, кош теле и другие кушанья, без которых не обходится ни один праздник.

Бәлеш рецепты

Продуктлар:

2,5 стакан он,
ярты стакан каймак,
ярты стакан кефир,
тоз,
3 бәрәңге,
суган,
ярты кило сыер ите,
төелгән кара борыч,
сыер ите шулпасы.





1. Каймак, кефир, бер чеметем тоз һәм онны бергә кушып болгатырга. Камырны 30 минутка сөлге астында калдырырга.
2. Сыер итен, бәрәңге, суганны вак итеп, шакмаклап турарга. Тоз һәм борыч өстәп болгатырга.
3. Бәлешнең капкачы өчен камырның өчтән бер өлешен аерып алырга. Калган өлешен юка итеп җәяргә һәм кырыйлары чыгып торырлык итеп формага урнаштырырга.
4. Камыр җәелгән формага эчлекне салырга. Өстенә түгәрәк итеп җәелгән камырны (капкачны) капларга һәм читләрен чеметеп ябыштырып чыгарга.
5. Капкачның уртасында кечкенә генә тишек ясарга, ә аннары аны түгәрәк камыр кисәге белән капларга.
6. 2 сәгать 30 минут пешерергә. 40 нчы минутта камыр кисәген алып, тишектән бераз шулпа салырга.

Рецепт бэлеша

Продукты:

2,5 стак. муки,
полстакана сметаны
и полстакана кефира,
соль,
3 картофелины,
луковица,
полкило говядины,
чёрный молотый перец,
говяжий бульон.

1. Смешать сметану, кефир, щепотку соли, муку. Оставить тесто на 30 минут под полотенцем.
2. Говядину, картошку, лук нарезать мелким кубиком. Добавить соль и перец, перемешать.
3. Отделить от теста одну треть – для крышки пирога. Оставшуюся часть раскатать в лепёшку и уложить в форму так, чтобы края теста выступали из неё.
4. В форму с тестом выложить начинку. Поверх положить круг теста (крышку) и защипнуть края.
5. В центре крышки сделать небольшое отверстие, а затем закрыть его шариком теста.
6. Выпекать 2 часа 30 минут. На 40 минуте убрать шарик из теста и через отверстие влить немного бульона.

Татары, как и другие народы Поволжья, славятся гостеприимством. Приход гостя – важное событие в доме. Для гостя обязательно накрывают стол и потчуют лучшими блюдами. Татары говорят: «С гостем в дом приходит и достаток».



Идел буендагы башка халыклар кебек үк, татарлар да кунакчыл булулары белән дан тота. Кунак килү – өйдә мөһим вакыйга. Кунак өчен һәрвакыт табын коралар һәм иң тәмле ризыклар белән сыйлыйлар. Татарлар: «Кунак белән өйгә муллык, бәрәкәт килә», – диләр.

ЧУВАШ ХАЛЫК КУХНЯСЫ

Чуваш халык кухнясы камыр ашларының төрлелеге белән аерылып тора. Чувашлар ярма, кәбестә, җиләк, яшелчә, эремчек, ит пироглары пешергәннәр.

Эчлеге ит (яки балык), бәрәңге һәм суганнан булган зур пирог – хуплуны камырдан ясалган бизәкләр белән бизиләр.

Пуремеч – эремчек ватрушкасы – һичшиксез, бәйрәм табынына бирелә.

ЧУВАШСКАЯ НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ

Чувашская национальная кухня славится разнообразием блюд из теста. Чуваши пекли пироги с крупой, капустой, ягодами, овощами, творогом, мясом.

Большой пирог хуплу с начинкой из мяса (или рыбы), картофеля и лука украшают узорами из теста.

Пуремеч – ватрушку с творогом – обязательно подают на праздники.

Хуплу пирогы рецепты

Продуктлар:

йомырка,
3 стакан он,
1 чәй кашыгы чүпрә,
1 аш кашыгы шикәр комы,
1 стакан су,
20 г атланмай,
1/4 стакан сөт;
400 г ит,
4 бәрәңге,
суган,
тоз,
кара борыч.

1. Су, сөт, шикәр комы, чүпрә һәм азрак онны бергә кушыгыз. Апараны 30 минутка җылы урынга куегыз.
2. Онның яртысын йомырка һәм апара белән кушыгыз. Он өстәп, камыр басыгыз һәм бер сәгатькә калдырыгыз.
3. Бәрәңге, ит һәм суганны зур булмаган шакмакларга турагыз, атланмай, тоз, борыч кушыгыз һәм болгатыгыз.
4. Камырның зуррак өлешен 0,5 см калынлыкта түгәрәкләп җәегез. Формага куеп, эчлекне салыгыз. Өстен икенче түгәрәк камыр җәймә белән каплагыз һәм кырыйларын чеметеп чыгыгыз. Уртасына зур булмаган тишек ясагыз.
5. 180 градуста кызарганчы пешерегез.

Рецепт пирога хуплу

Продукты:

яйцо,
3 стак. муки,
1 ч. ложка дрожжей,
1 ст. ложка сахара,
1 стак. воды,
20 г сливочного масла,
1/4 стак. молока;
400 г мяса,
4 картофелины,
луковицы,
соль,
чёрный перец.

1. Смешайте воду, молоко, сахар, соль, дрожжи и немного муки. Поставьте опару в тёплое место на 30 минут.
2. Половину количества муки смешайте с яйцом и опарой. Посыпая муку, замесите тесто и оставьте на час.
3. Картофель, мясо и лук нарежьте небольшими кубиками, добавьте сливочное масло, соль, перец и перемешайте.
4. Из большей части теста раскатайте круг толщиной 0,5 см. Положите в форму и выложите начинку. Накройте сверху другим кругом теста и защипните. В середине сделайте небольшое отверстие.
5. Выпекать до румяной корочки при температуре 180 градусов.

«Хуплу» сүзе чуваш теленнән «ябык ашамлык» дип тәрҗемә ителә. Пирогны ашау бик үзенчәлекле. Башта аның өске өлешен – «капкач»ын ачалар, аннары сусыл эчлеген кашык белән ашыйлар.

Слово «хуплу» переводится с чувашского языка как «закрытое блюдо». Едят пирог особым способом. Сначала снимают его верхнюю часть – «крышку», а затем едят сочную начинку ложками.

УДМУРТ ХАЛЫК КУХНЯСЫ

Удмуртларда бодай, солы, арыш, борчак һәм киндердән пешерелгән тәмле ашамлыклар күп. Төрле эчлекле пәрәпәч удмурт милли кухнясының иң атаклы ризыгы булып тора.

Шулай ук удмуртларда эчлеге кәбестә, торма, эремчек, гөмбәдән булган, пилмәнгә охшаган кечкенә бөккән – пельнянь бик популяр.

УДМУРТСКАЯ НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ

У удмуртов много разнообразных и вкусных блюд из пшеницы, овса и ржи, гороха и льна. Самым известным блюдом удмуртской национальной кухни являются перепечи – ватрушки с разными начинками.

Также у удмуртов популярны пельняни – маленькие пирожки, похожие на пельмени, с начинкой из капусты, редьки, творога или грибов.



Пәрәмәч рецепты

Продуктлар:

2 стакан кефир,

1/3 стакан
үсемлек мае,

1 йомырка, сода,

3 стакан арыш оны,

бер чеметем тоз
һәм шикәр комы (камыр өчен);

бәрәңге боламыгы,
фарш яки гөмбә,

сөт, йомырка
(эчлек өчен).

1. Арыш онынннан камыр басыгыз һәм зур булмаган түгәрәкләр ясагыз.
2. Аларны җәегез һәм читләрен күтәртеп бөгеп чыгыгыз.
3. Урталарына эчлек (бәрәңге боламыгы, фарш яки гөмбә) салыгыз.
4. Йомырканы сөт белән бутагыз һәм килеп чыккан катнашманы эчлеккә агызыгыз.
5. Пәрәмәчләрне 20 минутка 180 градуслы мичкә куегыз.

Рецепт перепечей

Продукты:



2 стак. кефира,

1/3 стак.
растительного масла,

1 яйцо, сода,

3 стак. ржаной муки,

щепотка соли
и сахара для теста;

пюре, фарш
или грибы,

молоко, яйцо
для начинки.

1. Замесите тесто из ржаной муки и сделайте небольшие шарики.
2. Раскатайте их и залепите края в корзиночку.
3. Положите в серединку начинку – пюре, фарш или грибы.
4. Смешайте яйцо с молоком и получившейся смесью полейте начинку.
5. Поставьте перепечи в духовку на 20 минут при температуре 180 градусов.

МИЛЛИ КУХНЯ

МОРДВА МИЛЛИ КУХНЯСЫ

Мордва милли кухнясы элеккеге вакытларда, нигездә, тары, арпа, ясмык, борчак һәм башка ярмадан пешерелгән боткалардан, бодай белененнән һәм сөт ризыкларыннан торган. Алдагы көннәргә дип, гөмбә, кәбестә тозлаганнар.

«Аю тәпие» («Офтонь мадят» (мукшы), «Овтонь лапат» (эрзя)) – арыш сохариеннан гыйбарәт кәтлит – иң үзенчәлекле ашамлыкларның берсе.

МОРДОВСКАЯ НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ

Мордовская национальная кухня в старину состояла в основном из каш из просяной, перловой, чечевичной, гороховой и других круп, пшеничных блинов и блюд из молока. Впрок заготавливали грибы, квасили капусту.

Одно из самых оригинальных блюд – «Медвежья лапа» («Офтонь мадят» (мокша), «Овтонь лапат» – представляет собой котлету с ржаными сухарями.

Эрзя һәм мукшы халыклары оста аучылар булган, шуңа күрә өстәлгә еш кына киек ите куелган.

Народы эрзя и мокша были прекрасными охотниками, поэтому на столе часто была дичь.

«Аю тәпие» ризыгы рецепты

Продуктлар:

300 г сыер бавыры,

300 г ит фаршы,



бер баш суган,

2 йомырка,

төелгән кара борыч,

тоз,

кәтлитләрне әвәләү өчен бераз он,

ак ипидән сохари.

1. Бавырны вакларга.
2. Туралган суган һәм йомырка, чыгарылган фарш кушып болгатырга.
3. Тоз һәм борыч өстәргә.
4. Кәтлитләрне әвәләп ясарга.
5. Һәрберсен башта – онда, аннары йомырка һәм сохарида әвәләргә.
6. Кәтлитләрне, әзер булганчы, майда кыздырырга.

Рецепт блюда «Медвежья лапа»

Продукты:

300 г говяжьей печени,



300 г мясного фарша,

луковица,

2 яйца,

чёрный молотый перец,

соль,

немного муки для обвалки котлет,

сухарики из белого хлеба.

1. Измельчить печень.
2. Смешать её с фаршем, порубленным луком и яйцом.
3. Добавить соль и перец.
4. Сформировать котлеты.
5. Обвалять каждую в муке, затем в яйце и сухариках.
6. Жарить котлеты на масле до готовности.

МАРИ МИЛЛИ КУХНЯСЫ

Мари милли кухнясы урман нигъмәтләре – һәртөрле ит, җиләк, гөмбә, үләннәр, балдан ясалган күптөрле ашамлыклары белән аерылып тора.

Мари хуҗабикәләре – оннан (төрле эчлекле кабартмалар, катламлы команмелна белене), ярмадан ашамлыклар һәм һәртөрле ашлар пешерүдә осталар. Мәсәлән, чукмарлы (пешкән камыр кисәкләре), борчак һәм гөмбәле лашка ашы.

МАРИЙСКАЯ НАЦИОНАЛЬНАЯ КУХНЯ

Марийская национальная кухня отличается разнообразием блюд из даров леса: всевозможных видов мяса, ягод, грибов, трав, мёда.

Марийские хозяйки – мастерицы готовить блюда из муки (пирожки с разными начинками, слоёные блины команмелна), круп и всевозможные супы. Например, мясной суп лашка с клёцками (варёными кусочками теста), горохом и грибами.



Мариларда бәрәңгене «икенче икмәк» дип атыйлар. Бәрәңгедән әзерләнгән ашамлыклар буенча мари кухнясы, мөгаен, белорус кухнясыннан гына калышадыр.

Картофель у марийцев называют «вторым хлебом». По количеству блюд из картофеля марийская кухня уступает, пожалуй, только белорусской.

Щыл подкогыльо (суда пешкән итле бөккән) рецепты

Продуктлар:

1 стакан он,

1/6 данә йомырка,

50 шәр г дуңгыз һәм бозау ите,

суган,

1 аш кашыгы атланмай,

кара борыч,
тоз.







1. Йомырка, он һәм тоздан төче камыр басарга.
2. Камырны юка итеп җәяргә.
3. Уртасына эчлекне салырга.

Эчлек өчен:

4. Чи итне турарга.
5. Суганны вакларга.
6. Ит һәм суганны кушып болгатырга, тоз һәм борыч сибәргә.
7. Ярымай формасында бөккәннәр ясарга, матур итеп чеметеп ябыштырып куярга.
8. Бөккәннәрне кайнап торган тозлы суда пешерергә.
9. Май сибәргә.

Кайнар килеш бирергә.

Рецепт Щыл подкогыльо (отваренные пирожки с мясом)

Продукты:

1 стак. муки,

яйцо 1/6 шт.,

по 50 г свинины и говядины,

луковица,

1 ст. ложка масла сливочного,

чёрный перец,
соль.

1. Из яйца, муки и соли приготовить пресное тесто.
2. Тесто тонко раскатать.
3. В середину кладется начинка.

Для начинки:

4. Нарубить сырое мясо.
5. Мелко нарезать лук.
6. Смешать мясо и лук, посыпать солью и перцем.
7. Сделать пирожки в форме полумесяца, красиво их защипнуть.
8. Отварить пирожки в кипящей подсоленной воде.
9. Полить маслом.

Подавать в горячем виде.

ЙОМГАКЛАУ

Кадерле дустым! Без республиканың иң күп санлы алты халкының искиткеч мәдәнияте дөньясына сәяхәтебезне тәмамладык.

Китапны укыганнан соң, син рус, татар, чуваш, удмурт, мордва һәм мари халыкларының мәдәнияте, традицияләре турында яңа белемнәр алдың. Хәзер син төрле халыкларның милли костюмнарына, аш-су, тел, бәйрәмнәренә хас үзенчәлекләрне беләсең. Гореф-гадәтләр һәм тарих кебек саклана торган мәкальләрдәге халык зирәклеге белән дә таныштың. Моннан тыш, син кече ватаныбыз – Татарстанда туып үскән күренекле шәхесләр турында укыдың. Аларның фидакарь тормыш юлы сиңа үрнәк булып хезмәт итсен.

Ата-бабаларың турындагы хәтерне һәм безнең күпмилләтле халкыбызның уникаль мирасын сакла.

Уңышлар сиңа, кадерле дустым!

ЗАКЛЮЧЕНИЕ

Дорогой друг! Мы завершили наше путешествие в прекрасный мир культуры шести самых многочисленных народов республики.

Благодаря книге ты узнал много нового о культуре и традициях русских, татар, чувашей, удмуртов, мордвы и марийцев. Теперь ты знаешь об особенностях их народного костюма, кухне, языке, праздниках. В пословицах тебе приоткрылась народная мудрость, хранимая, как обычаи и история. Кроме того, ты прочёл о великих уроженцах нашей малой родины – Татарстана. Пусть их достойная, плодотворная жизнь послужит тебе примером.

Береги память о предках и храни уникальное наследие нашего многонационального народа.

Удачи тебе, дорогой друг!

Эчтәлек

Милли бизәкләр
һәм орнаментлар 4

Милли
киемнәр 20

Милли телләр
һәм әдәбият 34



Күренекле
шәхесләр 48

Халык бәйрәмнәре
һәм уеннары 54



Милли
кухня 80

Содержание

Национальные узоры и орнаменты 4

Национальный костюм 20

Национальные языки и литература 34

Выдающиеся личности 48

Народные праздники и игры 54

Национальная кухня 80

ТАТАРСТАН. БЕЗ БЕРГӘ
ТАТАРСТАН. МЫ ВМЕСТЕ

Художественно-просветительское издание для детей
(на татарском и русском языках)

Автор проекта
Марат Ганиев

Руководитель проекта
Азат Ганиев

Главный редактор
Гульнара Головина

Литературная редакция:
Алсу Низамеева, Елизавета Семенская, Фаниса Макарова, Зухра Фасхиева

Художники-иллюстраторы:
Евгения Кобелева, Елена Бутрова, Анна Гаранина, Елизавета Семенская

Дизайн
Дмитрий Гиацинтов

Графическая вёрстка
Елена Шарапова

Музыкальная редакция:
Мария Сергеева, Рафаэль Бахтиозин

Руководитель IT отдела
Дамир Бариев

Технический директор
Ильдар Низаметдинов

Рецензент
Расима Шамсутдинова

Консультанты:
Ляйсан Низамова, Ирек Шарипов

Фактологические материалы предоставлены
Ассамблеей народов Татарстана и Домом Дружбы народов Татарстана

Эксперты культурно-этнографического контента:
Людмила Мусихина, заместитель председателя Совета РОО «Национально-культурная автономия марийцев Республики Татарстан», председатель МОО «Национально-культурная автономия марийцев Республики Татарстан»

Сильвия Чаркина, заместитель председателя РОО «Чувашская национально-культурная автономия в Республике Татарстан»

Наталья Сабитова, руководитель РОО «Национально-культурная автономия мордвы Республики Татарстан»

Павел Александров, заведующий отделом развития народного творчества ГБУ «Ресурсный центр внедрения инноваций и сохранения традиций в сфере культуры Республики Татарстан»

Любовь Тукаева, руководитель отдела этнокультурной деятельности Дома Дружбы народов Татарстана

Татарское детское издательство
Редакция Гульнары Головиной

420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru

Подписано в печать 23.11.2022
Печать офсетная. Тираж 8000 экз. Заказ №
Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных Татарским детским издательством материалов в типографии филиала АО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

ИДЕЛ БУЕ БАТЫРЛАРЫ

Татар, рус, чуваш, мари, мордва, удмурт халыкларының әкиятләренә нигезләнеп

2022 год культурного наследия народов России

АТӐЛ ПАТТӐРӖСЕМ • ВОЛЖСКИЙ ОНАР

КИТАП
КНИГА



волжскиебогатыри.рф



КАМЫР-БАТЫР

Татар халык әкиятләре мотивлары буенча татар һәм рус телләрендә.

По мотивам татарских народных сказок на татарском и русском языках.

ВОЛЬГА

Рус халык әкиятләре мотивлары буенча татар һәм рус телләрендә.

По мотивам русских народных сказок на татарском и русском языках.

ИВАН-БАТЫР • ЙӐВАН ПАТТӐР

Чуваш халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус һәм чуваш телләрендә.

По мотивам чувашских народных сказок на татарском, русском и чувашском языках.

МАРШАН

Мари халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус һәм мари телләрендә.

По мотивам марийских народных сказок на татарском, русском и марийском языках.

САБАН

Мордва халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус, эрзя һәм мукшы телләрендә.

По мотивам мордовских народных сказок на татарском, русском и языках эрзя и мокша.



СЕЛТА

Удмурт халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус һәм удмурт телләрендә.

По мотивам удмуртских народных сказок на татарском, русском и удмуртском языках.

По мотивам татарских, русских, чувашских, марийских, мордовских, удмуртских сказок

ВОЛЖСКИЕ БОГАТЫРИ

ВОЛЖСКИЙ БАТЫРЪЁС • РАВЧИРЕНЬ МАРАЛЯТ

ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ



МУЛЬТФИЛЬМНАР
МУЛЬТФИЛЬМЫ

волжскиебогатыри.рф

МЫ ВМЕСТЕ • БЕЗ БЕРГӘ • ТАТАРСТАН • МЫ ВМЕСТЕ • БЕЗ БЕРГӘ • ТАТАРСТАН • МЫ ВМЕСТЕ • БЕЗ БЕРГӘ

www.без-берге.рф

2022 ГОД КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ НАРОДОВ РОССИИ

ISBN 978-5-6046009-4-8

9 785604 600948

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ

6+

© Татарское детское издательство, 2022

www.tdpress.ru